Туган телем - иркә гөлем, киңдер сиңа күңел түрем...

# КҮМӘК КӨЧ

ГОМУМИ РАЙОН ТАТАР ГАЗЕТАСЫ
1930 елдан чыга.
Бәясе ирекле
№ 14 (10706)
Чәршәмбе,
5 апрель 2017 ел.
(Атнага бер тапкыр чыга)

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫЛАР: 1. УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ ХӨКҮМӘТЕ (432017, Ульяновск шәһәре, Ленин мәйданы, 1)2. "ИСКЕ КУЛАТКЫ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ БЕРЛӘШМӘСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ (433940, УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ, ИСКЕ КУЛАТКЫ ЭШЧЕЛӘР БИСТӘСЕ, ПИОНЕРСКАЯ УРАМЫ, 30)

## Герой безнең белән яшәр

**28 мартта, Иске Кулаткы район культура йортында, Россия Федерациясенең Герое, Сириядә һәлак булган якташыбыз, Көньяк хәрби округы авиациясе армиясенең 55 нче аерым вертолет полкының командиры Рәфәгать Махмутович Хәбибуллинның туган көненә багышланган тантаналы митинг булып үтте.**



"Безнең мәктәпләребез Р. Хәбибуллинны искә алып, киләчәктә дә хезмәттәшлек итәр", – дип белдерде.

Бу чара алдыннан Иске Кулаткы районының мәктәп укучылары арасында "Минем якташым - Россия Герое" дип исемләнгән сочинениеләр конкурсы игълан ителгән иде. Анда җиңүчеләр Почет грамоталары һәм район Башлыгы Э. Ә. Ганеевның бүләкләре белән билгеләнделәр.

Бу бәйгедә беренче урынга чыгучы Иске Мостяк урта мәктәбе укучысы Э. Латыпова үзенең сочинениесен сәнгатьле итеп укыды.

Митингта В. А. Деникаева "Офицеры", Резеда Абәйдуллина "Опустела без тебя земля", Давид Яфаров (гитарада), Иске Кулаткы икенче номерлы урта мәктәбе укучылары тарафыннан патриотик рухта башкарылган җырлар һәр кешенең күңелендә Герой - якташыбыз Р. Хәбибуллинның якты образын тудырды.

Сызрань шәһәренең югары хәрби авиация училищесының тын оркестрының уйнавы, аларның төз итеп басып торулары - һәркемнең игътибар үзәгендә булды. Чара тәмамлангач, район сугыш һәм хезмәт ветераннары Советы, элеккеге елларда кайнар нокталарда катнашучылар Рәфәгать Махмутович Хәбибуллинның истәлекле тактасы алдына венок куйдылар.

Бу зур чарада бихисап райондашларыбыз, читтән килгән кунаклар зур теләк белдереп катнаштылар. Алар арасында Рәфәгать Хәбибуллин исемен йөрткән Кореновск шәһәренең 3 нче номерлы урта мәктәбе директоры Г. А. Кайшев, Герой - якташыбыз укыган, профессор Н.Е. Жуковский һәм Ю.А. Гагарин исемнәрен йөртүче Сызрань шәһәренең югары хәрби авиация училищесының тынлы оркестр музыкантлары бар иде.

Тантаналы митинг нәкъ шушы оркестрның йөрәкләрне тетрәндергеч чыгышы белән башланды. Ә инде Иске Кулаткы балалар сәнгать мәктәбе укучыларының "Ак кошлар" дип исемләнгән биюе тамашачыларның күңелендә митингка карата тагын да кызыксыну уятты.

Әлеге чараны сәнгать мәктәбе педагоглары Л. Р. Байбикова һәм Л. Р. Амирова оста итеп алып бардылар. Алар үзләренең чыгышларында Иске Кулаткы район Башлыгы Э. Ә. Ганеевның яшь буынга хәрби-патриотик тәрбия бирүдә, Бөек Җиңүнең 70 еллыгына мемориаль комплекс, хәрби интернационалистларга обелиск төзүдә, Рәфәгать Хәбибуллинга истәлекле такта куюда зур эш башкарганын аеруча билгеләп үттеләр.

Аларның чыгышларыннан күренгәнчә, Рәфәгать Махмутович Хәбибуллинны мәңгеләштерү йөзеннән Краснодар шәһәренең бер урамына, Иске Кулаткы икенче номерлы урта мәктәбенә, үзе туган Вязовый Гай авылы клубына һәм югарыда әйтеп үткәнчә 3 нче номерлы Кореновск шәһәренең урта мәктәбенә аның исеме бирелгән. Якташыбызны данлау буенча алда да эшләр алып барылачак.

Аннан соң чыгышларны Ульяновск законнар җыены депутаты Г.А. Долгов, Ульяновск өлкә Хөкүмәтенең Иске Кулаткы районы буенча кураторы Р. Ш. Гайнетдинов, Иске Кулаткы район администрациясе Башлыгының кеше потенциалын үстерү буенча урынбасары В. А. Деникаева, Иске Кулаткы шәһәр поселениесе Башлыгы Р. А. Джаметов ясадылар. Алар яшь буынны тәрбияләүдә әлеге чараның әһәмиятлелеген ассызыкладылар һәм Р. Хәбибуллинның әнисе Гөлҗиһан апаның, туганнарының зур югалтуларын, кайгыларын уртаклашып, Герой - якташыбызның батырлыгына баш иделәр.

Р. Ш. Гайнетдинов әлеге чарадан файдаланып, "Ветеран" программасын реализацияләү кысаларында Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары А. Х. Сәйфуллинага һәм Х. Ш. Давыдовага (Яңа Терешка, Иске Атлаш) торак сертификатлары тапшырды.

Ә инде Кореновск шәһәренең 3 нче номерлы урта мәктәбе директоры Г. А. Кайшевның чыгышы йөрәкләрне тетрәндерде. Аның күз яшьләре аша Р. Хәбибуллинны искә алып сөйләве, якташыбызга карата ихтирамын чынбарлыкта күрсәтте. Ул Иске Кулаткы икенче номерлы урта мәктәбенә Кореновск мәктәбе укучыларының язма альбомын бүләк итеп:






Р. Хәбибуллинга багышланган чаралар алда да гөрләп торыр. Аны искә алып, быел 14 июльдә, Иске Кулаткы икенче номерлы урта мәктәбе территориясендә һәм туган Вязовый Гай авылының скверында бюстлар куелачак.

**Рөстәм АРИФУЛЛИН.**
**Автор фотолары.**

### В. В. Путин армиягә язгы чакыру турындагы указга кул куйды.

**Президент Владимир Путин гражданнарны хәрби хезмәткә чакыру указын имзалады. Документ нигезендә, 2017 елның 1 апреленнән 15 июльгә кадәр Россия Кораллы көчләренә 142 мең кеше җибәреләчәк.**



### ҖАВАПЛЫЛАР ҖАВАП ТОЙСЫН ИДЕ



**30 мартта без, «Күмәк көч" район газетасы журналистлары, халыкның соралуы буенча Иске Кулаткы эшчеләр поселогындагы урамнарның һәм юлларның торышын тикшерү максаты белән махсус рейд ясадык.**

**(Дәвамы 2 биттә).**

### Хөрмәтле газета укучыларыбыз!

**1 апрельдән 2017 елның икенче яртысына газетага рәсми рәвештә язылу башланды.**

Газетага ярты елга язылу бәясе - 397сум 80 тиен, бер айга - 66 сум 30 тиен, өч айга 198 сум 90 тиен тәшкил итәчәк. Газетаның бәясен халыкның матди хәлен исәпкә алып, күпкә арттырмадык.

**"КҮМӘК КӨЧ"** битләрендә район яңалыкларын белеп, истәлекле даталар белән котлау биреп, фотосүрәтләрдә танышларыгызның йөзләрен күреп, гаҗәеп кешеләр, район тарихы белән танышып һәм төпле киңәшләр алып була. Без сезнең мөрәҗәгатьләргә һәрвакыттагыча игътибарлы булып, сезне гел шатландырып кына торырга тырышырбыз. Район газетасы һәр өйгә керсен иде. Татар газетасы, татар районында һәрчак яшәсен дисәгез, элемтә бүлекчәләренә, хат ташучыларга мөрәҗәгать итеп, язылуыгызны көтеп калабыз.

| ПӘНҖЕШӘМБЕ (06.04.) | ҖОМГА (07.04.) | ШИМБӘ (08.04.) | ЯКШӘМБЕ (09.04.) | ДҮШӘМБЕ (10.04.) | СИШӘМБЕ (11.04.) | ЧӘРШӘМБЕ (12.04.) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| + 9 | + 11 | + 10 | + 9 | + 8 | + 4 | + 3 |
| + 3 | + 4 | + 3 | + 2 | - 2 | 0 | + 1 |

Официальная информация



**Информация об исполнении бюджета муниципального образования "Старокулаткинское городское поселение" за 2016 год**

| Наименование показателя | План | Кассовое исполнение |
|---|---|---|
| **Всего доходов** | **31689,8** | **32151,1** |
| в т.ч. | | |
| - собственные доходы | 12033,8 | 12573,7 |
| -безвозмездные поступления | 19656 | 19577,4 |
| **Всего расходов** | **32279,9** | **32197,2** |
| в т.ч. | | |
| -общегосударственные вопросы | 0 | 0 |
| -национальная оборона | 46,1 | 46,1 |
| -национальная безопасность и правоохранительная деятельность | 113,9 | 110,8 |
| -национальная экономика | 22316,1 | 22258,3 |
| -жилищно-коммунальное хозяйство | 7210,1 | 7188,4 |
| -культура, кинематография и средства массовой информации | 2593,7 | 2593,6 |

**Информация об исполнении бюджета муниципального образования "Старокулаткинский район" по состоянию на 01. 01. 2017г.**

| Наименование показателя | План | Кассовое исполнение |
|---|---|---|
| **Всего доходов** | **255029,0** | **256530,2** |
| в т.ч. | | |
| - собственные доходы | 20249,7 | 22593,6 |
| -безвозмездные поступления | 234779,3 | 233936,6 |
| Всего расходов | 256792,2 | 256364,3 |
| в т.ч. | | |
| -общегосударственные вопросы | 40233,1 | 40144,0 |
| -национальная оборона | 160,8 | 160,8 |
| -национальная безопасность и правоохранительная деятельность | 110,9 | 110,9 |
| -национальная экономика | 25067,0 | 24951,7 |
| -жилищно-коммунальное хозяйство | 5996,1 | 5975,0 |
| -образование | 126520,4 | 126473,3 |
| -культура, кинематография и средства массовой информации | 21358,4 | 21358,3 |
| -социальная политика | 26996,3 | 26944,8 |
| -физическая культура и спорт | 132,7 | 132,7 |
| -межбюджетные трансферты | 10216,5 | 10112,8 |
| **Численность муниципальных служащих органов местного самоуправления, шт.ед.** | 29,0 | |
| **Расходы на оплату труда муниципальных служащих органов местного самоуправления, тыс.руб.** | 8545,7 | |
| **Численность работников муниципальных учреждений, чел.** | 563 | |
| **Расходы на оплату труда работников муниципальных учреждений, тыс.руб.** | 144853,8 | |

**Глава администрации И.А. Аблязов.**

**АДМИНИСТРАЦИЯ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ "СТАРОКУЛАТКИНСКИЙ РАЙОН" УЛЬЯНОВСКОЙ ОБЛАСТИ**

**П О С Т А Н О В Л Е Н И Е**

**« 21 » марта 2017 г. р.п. Старая Кулатка № 68**

**Об организации и проведении комплекса работ по весеннему благоустройству территорий населённых пунктов муниципального образования «Старокулаткинский район»**

Во исполнение распоряжения Губернатора Ульяновской области от 17 марта 2017 года № 203-р «Об организации и проведении комплекса работ по весеннему благоустройству территорий населенных пунктов Ульяновской области» и в целях приведения в соответствии с санитарными нормами территорий населённых пунктов муниципального образования «Старокулаткинский район», администрация муниципального образования «Старокулаткинский район» п о с т а н о в л я е т:

1.Объявить и провести на территории муниципального образования «Старокулаткинский район» комплекс работ по весеннему благоустройству территорий населённых пунктов с 20 марта по 01 июня 2017 года.

2. Провести субботники по наведению чистоты и порядка, улучшению санитарного и экологического состояния населённых пунктов 14 апреля, 28 апреля, 5 мая, 19 мая 2017 года.

3. Объявить 19 мая 2017 года единым днём чистоты и порядка на территории муниципального образования «Старокулаткинский район».

4. Утвердить:

4.1.Состав комиссии по организации и проведению комплекса работ по весеннему благоустройству территорий населённых пунктов муниципального образования «Старокулаткинский район» (приложение №1).

4.2. План проведения комплекса работ по весеннему благоустройству территорий населенных пунктов муниципального образования «Старокулаткинский район» на период с 20 марта по 01 июня 2017 года (приложение №2).

5. Разработать и утвердить план закрепления сотрудников администрации муниципального образования «Старокулаткинский район» за территориями населенных пунктов муниципального образования «Старокулаткинское городское поселение» для осуществления координации работы по приведению территории в нормативное состояние.

6. Рекомендовать:

6.1. Главам администраций поселений:

6.1.1. Провести на территориях поселений комплекс работ по весеннему благоустройству территорий населённых пунктов в период с 20 марта по 01 июня 2017 года.

6.1.2. Создать комиссии по организации и проведению комплекса ра-бот по весеннему благоустройству территорий населенных пунктов.

6.1.3. Разработать и утвердить планы закрепления сотрудников администраций поселений за территориями населённых пунктов для осуществления координации работы по приведению территорий в нормативное состояние.

6.1.4. Обеспечить завершение весеннего осмотра зданий и сооружений с составлением актов в течение двух недель после окончания отопительного сезона.

6.1.5. В срок до 01 мая 2017 года завершить обследование территорий населенных пунктов на предмет незаконных строений и незаконно размещенных рекламных конструкций.

6.1.6. Разработать, утвердить и представить в администрацию муниципального образования «Старокулаткинский район» планы проведения комплекса работ по весеннему благоустройству территорий населенных пунктов.

6.1.7. В рамках проведения комплекса работ по весеннему благоустройству привлечь к работам на территории населённых пунктов коллективы организаций всех организационно-правовых форм, образовательных организаций, общественных организаций, население по месту жительства. Особое внимание обратить на очистку придомовых территорий, контейнерных площадок, скверов, зон отдыха, на ликвидацию стихийных мест скопления твёрдых бытовых отходов.

6.1.8. Организовать и провести конкурсы среди организаций по качеству благоустройства закрепленных территорий с еженедельным подведением итогов и вручением победителям переходящего вымпела.

6.1.9. В срок до 01 апреля 2017 года разработать комплекс культурно-досуговых и физкультурно-оздоровительных мероприятий в местах массового пребывания граждан.

6.1.10. В срок до 01 мая 2017 года обеспечить приведение в нормативное состояние существующих малых архитектурных форм и заключение договоров на установку новых малых архитектурных форм.

6.1.11. Обеспечить еженедельное размещение в средствах массовой информации материалов о проведении работ по благоустройству.

6.1.12. Представлять два раза в неделю (в понедельник и четверг) в администрацию муниципального образования «Старокулаткинский район» на бумажном носителе информацию о проведении комплекса работ по весеннему благоустройству.

Итоговый отчет о проведении комплекса работ по весеннему благоустройству территорий населенных пунктов представить 02 июня 2017 года.

6.2. Руководителям организаций всех организацинно - правовых форм собственности еженедельно по четвергам проводить санитарный день по уборке закреплённых территорий.

6.3. Редакции районной газеты «Кумяк кюч» обеспечить агитационную и разъяснительную работу по привлечению населения к участию в проведении комплекса работ по весеннему благоустройству территорий населенных пунктов, а также информирование населения о ходе проведения мероприятий.

7. Контроль за исполнением настоящего постановления возложить на первого заместителя главы администрации муниципального образования «Старокулаткинский район».

8. Настоящее постановление вступает в силу с момента его официального обнародования.

**Глава администрации И.А.Аблязов.**

**Закон и порядок**

## Об ответственности за продажу спиртосодержащей непищевой продукции.

Мировым судьей судебного участка Старокулаткинского района Радищевского судебного района Ульяновской области принято решение о привлечении к административной ответственности продавца магазина, принадлежащего индивидуальному предпринимателю, за розничную продажу спиртосодержащей непищевой продукции.

Факт совершения правонарушения был обнаружен участковым уполномоченным полиции МО МВД России «Павловский» Ульяновской области. Так 11 января 2017 года в 15ч. 40 мин. продавец из магазина «Алтын» реализовала спиртосодержащую непищевую продукцию с содержанием этилового спирта более 25%, а именно лосьон «Вита-Септ космо плюс» с содержанием этилового спирта 95% объема готовой продукции в нарушение Постановления Главного государственного санитарного врача Российской Федерации от 23.12.2016г. № 195 «О приостановлении розничной торговли спиртосодержащей непищевой продукции». На продавца был составлен протокол об административном правонарушении по ст.14.2 КоАП РФ.

Административная ответственность за незаконную продажу товаров (иных вещей), свободная реализация которых запрещена или ограничена, предусмотрена статьей 14.2 Кодекса Российской Федерации об административных правонарушениях и влечет наложение административного штрафа на граждан в размере от 1500 рублей до 2000 рублей с конфискацией предмета административного правонарушения или без таковой, на должностных лиц - от 3000 рублей до 4000 рублей с конфискацией предмета административного правонарушения или без таковой, на юридических лиц - от 30000 рублей до 40000 рублей с конфискацией предмета административного правонарушения или без таковой.

**Э.Х. ЯФАРОВА,**
**Мировой судья.**

## Вниманию населения!

В целях предупреждения нарушений юридическими лицами и индивидуальными предпринимателями обязательных требований лесного законодательства, устранения причин, факторов и условий способствующих нарушениям обязательных требований, руководствуясь положениями ст.8.2 Федерального закона от 26.12.2008г. № 294-ФЗ«О защите прав юридических лиц и индивидуальных предпринимателей при осуществлении государственного контроля (надзора), муниципального контроля» разъясняется:

Основным нормативно-правовым актом, устанавливающим обязательные требования к осуществлению деятельности юридических лиц и индивидуальных предпринимателей, соблюдение которых подлежит проверке в процессе осуществления федерального государственного лесного надзора (лесной охраны) и федерального государственного пожарного надзора в лесах является Лесной кодекс Российской Федерации (Собрание законодательства Российской Федерации, 2006, N 50, ст. 5278; 2008, N 20, ст. 2251; N 30, ст. 3597, 3599, 3616; N 52, ст. 6236; 2009, N 11, ст. 1261; N 30, ст. 3735; N 52, ст. 6441). Кроме Лесного кодекса РФ лесные отношения регулируются другими федеральными законами и принимаемые в соответствии с ними законами субъектов Российской Федерации, указами Президента РФ, постановлениями Правительства РФ и другими нормативными правовыми актами, регулирующими лесные отношения.

Лесное законодательство регулирует лесные отношения. Имущественные отношения, связанные с оборотом лесных участков и лесных насаждений, регулируются гражданским законодательством, а также Земельным кодексом Российской Федерации, если иное не установлено Лесным кодексом РФ, другими федеральными законами.

На основании Лесного кодекса РФ разработаны 14 Правил использования лесов и 7 порядков, относящихся к нормативно-правовым актам, устанавливающими обязательные требования к осуществлению деятельности юридических лиц и индивидуальных предпринимателей.

Спецификой проверок юридических лиц и индивидуальных предпринимателей при осуществлении федерального государственного лесного надзора (лесной охраны) и федерального государственного пожарного надзора в лесах, является соблюдение требований, обязательных для исполнения юридическими лицами и индивидуальными предпринимателями в зависимости от вида использования лесов.

На территории Старокулаткинского района в соответствии с заключенным договором аренды с юридическим лицом леса используются по следующим видам: заготовка древесины.

Соответственно при осуществлении федерального государственного лесного надзора и федерального государственного пожарного надзора в лесах проверяются требования, относящиеся к данным видам использования лесов, а именно:

- правила лесоразведения;
- правила пожарной безопасности в лесах;
- правила санитарной безопасности в лесах;
- правила лесовосстановления;
- правила ухода за лесами.
- правила заготовки древесины.

Арендатор для использования своего участка по виду использования, указанному в договоре аренды, должен составить проект освоения лесов на арендованный участок лесного фонда (ст. 88 ЛК РФ), в соответствии с лесохозяйственным регламентом лесничества и лесным планом субъекта.

В ходе осуществления надзора, так же проверяется соблюдение требований, установленных данными документами.

Передача осуществления отдельных полномочий Российской Федерации в области лесных отношений органам государственной власти субъектов Федерации выстроила новую модель лесных отношений. Изменилась структура управления лесами, виды правоустанавливающих документов на лесные участки, расширились виды использования лесов, а также распределились обязанности между органами исполнительной власти в области лесных отношений и арендаторами. На арендаторов, помимо разрешенного вида использования лесного участка, возложен весь комплекс мероприятий по охране, защите и воспроизводству лесов, отводу и таксации лесосек, в соответствии с проектом освоения лесов.

**ГКО УО "Старокулаткинское лесничество".**

### Об изменениях условий предоставления мер социальной поддержки на оплату жилищно-коммунальных услуг

В соответствии со статьёй 160 Жилищного кодекса Российской Федерации компенсации расходов на оплату жилых помещений и коммунальных услуг предоставляются гражданам при отсутствии у них задолженности по оплате жилых помещений и коммунальных услуг или при заключении и (или) выполнении гражданами соглашений по её погашению.

С января 2017 года в Ульяновской области, в соответствии с введёнными нормами законодательства, ежемесячная денежная компенсация расходов на оплату ЖКУ предоставляется гражданину при отсутствии у него задолженности по оплате жилого помещения и (или) коммунальных услуг, взноса на капитальный ремонт общего имущества в многоквартирных домах за три месяца подряд или при заключении и (или) выполнении гражданином соглашения по её погашению.

Расчёт размера компенсации производится ежемесячно по сведениям организаций жилищно-коммунального хозяйства о начисленных суммах за потреблённые жилищно-коммунальные услуги.

Получатели компенсации осуществляют оплату начисленных им платежей за жилое помещение и потреблённые коммунальные услуги. Органы социальной защиты населения предоставляют компенсацию понесённых расходов на оплату ЖКУ в объёме, установленном законодательством.

Поэтому, ещё раз напоминаем всем гражданам о необходимости своевременно и в полном объёме оплачивать жилищно-коммунальные услуги.

Обращаем внимание, что предоставление указанной компенсации может быть приостановлено в случаях:

- неуплаты получателем текущих платежей за жилое помещение и коммунальные услуги в течение трёх месяцев подряд (по информации организаций жилищно-коммунального хозяйства);
- не выполнения получателем компенсации условий соглашения по погашению задолженности по оплате ЖКУ (по информации организаций жилищно-коммунального хозяйства).

Чтобы вновь получать ежемесячную денежную компенсацию расходов на оплату ЖКУ гражданину будет необходимо погасить всю задолженность или заключить соглашение о её погашении и выполнять его условия.

В целях повышения платёжеспособной дисциплины и своевременного получения в полном объёме мер социальной поддержки по оплате ЖКУ рекомендуем всем получателям компенсации расходов на оплату ЖКУ быть внимательными при внесении платы за жилое помещение и потреблённые коммунальные ресурсы в целях недопущения образования задолженности за эти услуги.

Мәдәният тормышы

# Алар булган җирдә һәрчак бәйрәм



25 март көнне район мәдәният йортында мәдәният хезмәткәрләре һөнәри бәйрәмнәрен билгеләп үттеләр. Бирегә җәмгыятьнең рухи үсешенә һәм бай мәдәни мирасыбызны популярлаштыруга өлеш кертүче, мәдәниятнең үткәненә, хәзергесенә һәм киләчәгенә битараф булмаган кешелер: әлеге өлкәдә хезмәт иткән ветераннар, мәдәният хезмәткәрләре, район мәдәният каршында эшләп килүче халык театрының һәвәскәрләре, китапханәчеләр, сәнгать мәктәбе педагоглары, музей хезмәткәрләре һәм район җитәкчеләре чакырылган иделәр.

Бәйрәм тәбрикләү сүзләренә дә, җыр-моңга да бай булды.

Иске Кулаткы район администрациясе Башлыгы И.А. Аблязов ихлас күңелдән мәдәният хезмәткәрләрен һөнәри бәйрәмнәре белән котлап, халык театры җитәкчесенә һәм һәвәскәрләренә, ел дәвамында эшләрендә зур уңышларга ирешүче мәдәният хезмәткәрләренә: Зирекле авылы клубы мөдире Д.А. Хамзинага, Иске Кулаткы үзәкләштерелгән китапханә челтәре методисты Ә.К. Алтынбаевага, сәнгать мәктәбе педагогы Г.Ә. Сәйфуллинага Почет грамоталары тапшырды.

Чираттагы котлау сүзләрен район администрациясе Башлыгының кеше потенциалын үстерү буенча беренче урынбасары В.А. Деникаева ирештерде.

- Мәдәнияттә талантлы кешеләр, үз һөнәренең осталары эшли. Сез халыкның рухи байлыгын үстерүдә күп көч куясыз. Район данын өлкәгә, Россиягә танытасыз. Үзегезгә алмашка яшь буын тәрбияләүдә дә актив эшлисез. Үрнәк өлгесен төшермәгез, гел шулай уңышларга гына ирешергә язсын, - диде ул.

Район культура идарәсе начальнигы Ф.А. Кузәева да коллегаларына җылы теләкләрен юллады, киләчәктә дә мәдәниятне үстерергә, рухи байлыкны сакларга, нәтиҗәле эш алып барырга теләде.

“РФнең атказанган мәдәният хезмәткәре" исемен йөртүче, халык театрын озак еллар әйдәп баручы Р.Х. Аввәсов та кунакларны бәйрәм белән котлап, тормышында театр һәм сәхнәнең мөһим роль уйнавы турында сөйләде, дулкынланып үткән елларны искә алды.

Район мәдәният тормышында актив катнашып, мәдәниятне үстерүдә байтак өлеш кертүче А.У. Апсалямов элеккеге елларда мәдәният йортының эшчәнлеге, казанышлары турында сөйләде.

Ә инде Ульяновск шәһәренең халык мәдәният үзәге каршында эшләп килүче иң яхшы халык, үзешчән коллективларының искиткеч матур чыгышлары бәйрәмгә ямь өстәп, тамашачылар тарафыннан җылы кабул ителде.

“Яңа көн” балалар вокаль студия җитәкчесе Валерия



Шепелева, “Хыял тамчылары” балалар вокаль ансамбле ( җитәкчеләре Алсу Альметова), “Эрзань койть” мордва җырларының халык коллективы (җитәкчеләре А.Н. Чурбанов), “Ван” әрмән хореография ансамбле (җитәкчеләре Аида Бабаян), “Сарнай” чуваш җырларының ирләр ансамбле (җитәкчеләре Виктор Коваленко) милли киемнәрдән чуваш, мордва, татар телләрендә җырлар башкарып, әрмән халкының биюләрен күрсәтеп, регионыбызның төрле милләтләргә бай булуы, аларның үзара дус-тату яшәүләрен исбатладылар. Башка милләт вәкилләре белән уртак тел табып, аларны хөрмәт итеп, җыр һәм биюләрне уртак иткәндә, без илебез күгендә тынычлык һәм иминлек булдырачакбыз.

**Әлфия ЯФАРОВА.**

Культура

# Сохраним свои традиции



18 марта в доме культуры сел Бахтеевка и Чувашская Кулатка проведено праздничное мероприятие, посвященное Дню чувашской культуры. Со словами приветствия выступил администратор сел Бахтеевка и Чувашская Кулатка Х. Х. Саляев. В своей речи он особое внимание уделил на сохранение родного языка, культуры и самобытности чувашского народа. Сохранение традиций и обычаев – одно из условий продолжения существования чувашского народа. Особенностью культуры чувашского народа является совместное проживание с татарами, совместная и успешная работа в кооперативе «Бахтеевский», а также проведение совместных мероприятий с участием школы, бибилиотеки и дома культуры. Активное участие в проведении Дня чувашской культуры принимала группа «Подснежники». В исполнении Ольги Безрученко, Марии Мансуровой, Риммы Аминовой, Ларисы Хурасевой, Любы Сыбатровой прозвучали душевные и трогательные песни на чувашском языке. Очень тепло был принят номера в исполнении Эльвиры Хайровой, Ильхама Адельшина и Венеры Невмятуллиной. Сохранение чувашского языка – одно из условий продолжения культуры чувашского народа. Учащиеся Бахтеевской основной школы Иона Михайлова (2 класс) и Илюша Хурасев (6 класс) очень выразительно прочитали стихи на родном чувашском языке. Всем понравилась сценка в исполнении фольклорной группы «Подснежники». Ученик 5 класса Павел Безрученко исполнил песню о маме. Праздничное мероприятие завершилось благодарственной речью настоятеля храма, Батюшки Ильи Арланова, который призвал сохранить и беречь культуру чувашского народа.

**Мария МАНСУРОВА.**

2 апрель – Халыкара балалар китабы көне

# Китапханәдә кунакта

Күптән түгел генә Иске Кулаткы беренче һәм икенче номерлы урта мәктәпләренең I сыйныф укучылары үзләренең класс җитәкчеләре белән район үзәкләштерелгән балалар китапханәсендә кунакта булдылар. Балаларны шат күңел белән китапханәчеләр Ә.Р. Рәхмәтуллина һәм Г.Х. Бекирова каршы алдылар.



Бу көнне матур традиция буларак “Китапханә – әкияти дөнья” дигән баш астында беренче сыйныфларны китапханә укучыларына кабул итү бәйрәме оештырылды.

Китапханәчеләр кунакларны китаплар белән таныштырдылар, китапның һәрчак яхшыга гына өйрәтүен һәм белемле, әдәпле, акыллы киңәш бирүен, хезмәт сөючән, күркәм кеше булып үсәргә ярдәм итүен, туган илне сөяргә, авыр вакытта югалып калмаска өйрәтүен сөйләделәр. Китапларны саклап тоту кагыйдәләрен аңлаттылар, балалар абонементы эшчәнлеге белән таныштырдылар.

Бәйрәм әкияти геройларсыз башка үтмәде. Иске Кулаткы беренче номерлы урта мәктәбенең IV сыйныф укучылары Элина Яфарова һәм Ксения Ханбикова укытучылары Д.Н. Бахтиярова җитәкчелегендә Библиогномуслар буларак, кичәне бизәделәр. Балалар төрле кызыклы сорауларга җавап бирделәр, уеннар уйнадылар.

Әлеге очрашу балалар күңелендә онытылмас тәэсирләр калдырды.

**Әлфия ДАВЫДОВА.**

Мәгариф

# Иң дус сыйныф

Безнең балалар, Иске Кулаткы икенче номерлы урта мәктәбенең IX сыйныф укучылары,читтән торып үткән этапның сынауларын уңышлы үтеп, “Иң яхшы сыйныф” исемле гомуми белем бирү оешмаларының сыйныфлар коллективлары финалына чыктылар. Әйтергә кирәк, әлеге турда 34 команда катнашты.

16 март көнне балаларыбыз сыйныф җитәкчеләре Зөлфия Рушановна Алтынбаева белән бергә әлеге бәйгенең финалында катнаштылар. Биредә һәр районны данлаучы команда жюри әгъзаларын, тамашачыларны үзләренең сәләтләре, җиңүгә омтылулары белән сокландырдылар. Безнең команда да бәйгедә бар осталыкларын күрсәтеп, лаеклы чыгышлар ясады.

Конкурсантларга төрле биремнәр үтәделәр. Беренчесе – сыйныфның иҗади визиткасы, икенчесе – стенгазета, өченчесе – тематик мәйданчыкларның биремнәре иде.

Ә инде без, ата-аналар, спорт бәйгеләрендә көч сынаштык. Сыйныф җитәкчебез З.Р. Алтынбаева "Музыкаль биатлон" да үзенең иҗади сәләтен күрсәтте. Конкурс нәтиҗәләре буенча безнең балалар “Иң дус команда” номинациясендә җиңү яулады һәм Ульяновск өлкәсенең мәгариф һәм фән Министырлыгының дипломнары һәм истәлекле бүләкләре белән бил-



геләнде.

Без, ата-аналар, балаларыбызны һәм тулаем мәктәп коллективын әлеге уңышлары белән котлыйбыз.

Әлеге конкурска әзерләүдә ярдәм күрсәткән өчен мәктәп дирекциясенә, укытучылар Ф.И. Ханбиковага, В.А. Винюсевка олы рәхмәтебезне җиткерәбез. Яныбызда булучы, безгә җиңүгә көч-дәрт бирүче ярдәм төркеме - С.Ф. Нугаевага, К.С. Сәлимовка тирән ихтирамыбызны һәм рәхмәтебезне белдерәбез. Ышанабыз, балаларыбыз зур уңышлары, зур җиңүләре белән алда да безне куандырырлар.

**Ата-аналар исеменнән
Л.Р. РАХИМОВА.**

Ихтирамга лаек шәхесләр

# Бала күңелен аңлаучы

**Тәрбияче – бик олы хезмәт, чөнки баланың дөньяны бәхетле итеп күрәме, начар яктан күрәме - болар барысы да тәрбияче хезмәтеннән тора. Чын тәрбияче барлык мәхәббәтен, йөрәк җылысын балаларга бирергә, замана белән бергә атлап, балалар тәрбияләү өчен һәрвакыт эзләнергә, яңалыклар ачарга, яңа идеяләр белән янарга тиеш.**

Таһирә Таһировна Азизованы Иске Кулаткы районында сәләтле тәрбияче, тәҗрибәле хезмәткәр буларак беләләр. Тәрбияләү эшләрен ул, беренче чиратта, балаларны чын күңелдән ярату аша башкара. Ярату – кеше күңелен яктыртып торучы кояш ул. Кояш җылысыннан башка җир йөзендә тереклек булмас иде. Әгәр үзеңнән чын кешелеклелек, ярату хисләре бөркелеп тормаса, балада шәфкатьлелек, әдәплелек тәрбияләп булмый. Ә инде Таһирә Таһировнаның балаларны яратып тәрбияләве әллә кайдан күренеп тора.



Ул Ферган өлкәсе Узбекистан районы Шор-Су поселогында ишле гаиләдә туа. Мәктәпне тәмамлагач, тырыш, өлгер, яшь кыз балалар бакчасына эшкә керә һәм читтән торып Коканде шәһәрендәге педагогия училищесында тәрбиячеләр бүлегендә белем ала. 1989 елда гаиләсе белән Иске Кулаткыга кайта. Ул елларда Рәисә Якубовна Мусина җитәкләгән "Кояшчык" балалар бакчасына эшкә урнаша.

Тәрбияче... Әлеге һөнәр иясеннән иҗади сәләт тә, көндәлек җаваплылык та, сабырлык та, кечкенә генә уңышны зур итеп кабул итә белү дә таләп ителә. "Бала чактан алган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас".

"Бу бөек сүзләрнең асылына төшенсәң, балалар бакчасында эшләүче тәрбияченең нинди җаваплы эш башкаруын аңларсың", - дип әйткәннәр аңа үз тәҗрибәләре белән уртаклашкан коллегалары. Хезмәтен Иске Кулаткы 3 нче номерлы "Чишмә" балалар бакчасында дәвам иттергәндә дә, әлеге мөлаем ханым үз урынын таба һәм безнең, коллегаларының, ата-аналарның, балаларның ихтирамын яулый.

Таһирә Таһировна 38 ел тәрбияче булып эшләү дәверендә тәрбияче эше - һөнәренә генә түгел, ә инде тормышына, яшәешенә әйләнде. Күпме сабыйларга наз һәм йөрәк җылысын биргән. Әле инде кайберәүләренең үз балалары да үсеп, аның тәрбиясенә тапшырылды.

- Мин балалар белән үткән һәр көнгә сөенәм. Аларның минем янга колач җәеп йөгереп килүләре, ашыга-ашыга минем белән кызыклы яңалыкларын уртаклашулары – олы куаныч. Минем фикеремчә, бу тәрбияче өчен иң олы бәя, барлык мактаулардан да өстен.

Гомеремне балалар арасында уздырганга, бер дә үкенмим. Киресенчә, әлеге әкияти балачак иленә дә мин барлык тормыш мәшәкатьләремне онытып, үземне яшь, энергияле, сәламәт итеп хис итәм, - дип горуланып әйтә үзенең хезмәте турында Таһирә Таһировна.

Балалар бакчасында үткәрелә торган барлык бәйрәмнәр дә аның катнашуы белән үтә, ул зур теләк белән төрле рольләрне дә башкара. Намуслы эше өчен Ульяновск мәгариф һәм фән Министрлыгы, район мәгариф бүлеге исемнәреннән күп тапкыр Мактау хатлары белән бәяләнде. Олы йөрәкле коллегабыз һәрбер балага, тәрбиячегә, ата-анага мәрхәмәтлелеге, ярдәмчеллеге, кешелеклелеге белән зур хөрмәткә лаек.

Шәхси тормышы да аның үрнәк итеп сөйләрлек. Ул гаиләдә тырыш, хезмәт сөючән, уңган ана, хуҗабикә. Тормыш иптәше Расим Абдулхакович белән дус-тату яшәп, ике бала тәрбияләп үстерделәр, олы тормыш юлына бастырдылар. Хәзер инде балалары үз гаиләләре белән Иске Кулаткыда гомер кичерәләр.

Кызлары Луиза ул үстерә, ә кече кызлары Эльгиза тормыш иптәше Руслан белән кыз һәм ул тәрбиялиләр. Таһирә Таһировна алар өчен - төпле киңәшче дә, нык таяныч та, җылы кочак та.

Шушы көннәрдә Таһирә Таһировна үзенең гомер бәйрәмен билгели. Балалар бакчасы коллективы, ата-аналар, нәниләр аны истәлекле юбилее белән кайнар котлый, исәнлек-саулык, тыныч тормыш, куанычлы көннәр, тынгысыз хезмәтендә уңышлар, күңел күтәренкелеге теләп кала.

**Гөлсинә СӘЛӘЕВА,
"Чишмә" балалар
бакчасы мөдиренең
урынбасары.**

# Саф күңелле Зөһрә апа



***Кеше гомерен тиккә генә табигать фасыллары белән чагыштырмыйлар. Аның да бит бөреләнгән, чәчәк аткан, тажын койган мәлләре бар. Балачак, үсмерчак, яшьлек, өлгерәнлек, өлкәнәю...***

Күп чорлар яшәлгән, артка әйләнеп карасаң, яшәлмәгән дә кебек. Әммә һәр ел фасылының матурлыгы булган кебек, кеше гомеренең дә һәрбер чоры үзенә генә хас булган бер матурлыкка ия. Менә безнең юбилярыбыз да 8 апрель көнне үзенең 55 нче язын каршы ала. Мөгаен, еллар ялгышкандыр, әле җете җәйләр төсе анда: бит очларын чокырайтып, күзләреннән нур чәчеп елмайганда, яшәү дәрте бөркелеп-ташып тора үзеннән. Зөһрә апа Усманова Кирюшкино авылының тырыш, уңган һәм хөрмәткә лаеклы колхозчылар Марифә апа һәм Яхъя абый Юнусовларның 5 балалы тату гаиләсендә дүртенчеләре булып дөньяга килә. 2 малай, 3 кыз тупырдап, берсен-берсе карап, туганлыкның кадерен белеп үсәләр. Кечкенә Зөһрә да Расимә һәм Фатыйма апаларына, Әдһәм абыйсына ияреп, бик яшьтән кул арасына керә башлый. Әти-әниләренә хуҗалык эшләрендә дә, кечкенә энеләре Хамзәне тәрбияләүдә дә ярдәм итәләр. Еллар уза. Зөһрә апа Кирюшкино авылы мәктәбендә уңышлы гына 8 нче сыйныфны тәмамлый һәм укуын Иске Кулаткы эшчеләр поселогында дәвам итә. Яшь кыз уңышлы гына кибетчеләр хәзерләү курсларын тәмамлый. Нәкъ шул вакытта ул гомерлек мәхәббәтен дә очрата. Иске Кулаткы егете Ринат Батырхан улы Усманов белән матур гаилә корып җибәрәләр. Язмыш җилләре яшь гаиләне Самарканд шәһәренә күченеп китәргә мәҗбүр итә. Кечкенәдән үк хезмәттә чыныгу алып үскән яшьләр шәһәрдә дә югалып калмыйлар. Зөһрә апа ипи пешерү комбинатына эшкә урнаша. Гаиләләрен тулыландырып, Рамил һәм Равил исемле уллары туа. Тормышлары шулай матур гына алга таба дәвам итә. Чит җирләрдә яшәү нинди генә матур булса да, олыгайган саен туган як үзенә тарта башлый. Усмановларның гаиләсе дә туган якларын сагынып, ялгызы гына калган әниләре Марифә апа янына, төп нигезгә кайталар. Авылда эш булмау сәбәпле, Зөһрә апаның тормыш иптәше Ринат абый да, уллары Рамил белән Равил да бүгенге көндә Мәскәү шәһәрендә вахта ысулы белән хезмәт итәләр.

"Әти-әни хакы барысыннан да өстен бит, шуңа да мин гаиләм белән ялгыз яшәүче әнием янына кайттым. Төп йортыбыз, туган нигезнең җылысын саклап яшәргә тырышам. Аллага шөкер, тормыш иптәшем дә, улларым да минем беренче ярдәмчеләрем. Әниемә тәрбия күрсәтеп яшәвем белән мин бик бәхетле," – ди Зөһрә апа.

Кирюшкино авылында яшәүче Расимә апа да сеңелесе адресына гел мактау сүзләре генә житкерә. "Ходайга шөкер, бүген бишебез дә исән-имин. Шәһәрдә яшәүче бертуганнарыбыз әниебезне сагынып балалары, оныклары белән төялешеп кайталар. Очрашуларыбыз һәрвакыт бәйрәмгә әверелә. Сеңелебез әнием белән безне сөенә-сөенә каршы алалар. Мунчаны ягып, тәмле бәлешләрне пешереп көтәләр. Зөһрәбезнең тормыш иптәше дә, уллары да авыл җанлы, хезмәт сөючәннәр. Туган йортыбызны гел матурайтып, төзекләндереп торалар. Йортларын тутырып мал-туар, кош-корт асрыйлар. Истәлекле юбилее уңаеннан яраткан сеңелебезгә иң матур теләкләребезне генә җиткерәбез. Саулыкта, исәнлектә озын гомер кичерүен телибез."

Зөһрә апа туган авылының хозур табигатенә гашыйк ул, үзе дә бакча тутырып гөлләр үстерә, туганнарын яшелчә, җиләк-җимеш белән сыйлый, телеңне йотарлык камыр ашлары пешерә. Бу көннәрдә Зөһрә апа Усманова якыннарының, туганнарының ихлас котлауларын кабул итә. Ә ял көнендә аның якыннары, яраткан апалары, абыйсы һәм энесе котларга дип гаиләләре белән шау-гөр килеп кайтып төшәчәк. Газиз әниләре янына, тату гаилә тагын нигез йортта, мул сыйлы юбилей табыны артында җыелачак. Иң кадерле, иң җылы котлау сүзләренә редакция коллективы да кушыла. Истәлекле юбилеегыз белән котлап, гомернең иң озынын, бәхетнең иң зурысын, шатлыкның иң олысын телибез. Гаиләгезгә тигезлеге, җан тынычлыгы, яхшы, күтәренке кәеф юлдаш булсын. Һәрвакытта да шулай шат, көләч йөзле, изге күңелле, ихтирамлы, игътибарлы булып, балаларыгызның, якыннарыгызның изгелеген күреп, мул тормышта яшәргә Ходай насыйп итсен.

*Тормыш юлың һәрчак
балкып торсын,
Ягымлы, шат булсын
күңелең.
Озын гомер, бәхет -
шатлык белән
Бер кайгысыз үтсен
гомерең.*

**Гөлназ КУЗӘЕВА.**

# ТӘБРИКЛӘҮЛӘР КАБУЛ ИТЕГЕЗ!

**Карамалы авылында гомер итүче Разыя Абубәкәровна ЗАБИРОВА 3 апрельдә 80 яшьлек юбилеен билгеләде.**

**Дөньяда иң кадерле кешебез – сөекле, газиз, яраткан әниебез, әбекәебез!**

Сине чын күңелдән гомер бәйрәмең белән котлыйбыз. Кадерлебез, күпләргә үрнәк булырлык тормыш юлы үттең, сугыш елларының авырлыкларын татып үскән, гүзәл яшьлек елларын иң авыр хезмәткә багышлаган авыл баласы. Гомер буе намуслы хезмәт куеп, авылдашларыңның ихтирамын яуладың. Сигезенче дистәне тутырсаң да, күңелең белән һаман яшь әле. Без сине шәфкатьле, олы җанлы, сабыр, ярдәмчел булуың өчен яратабыз. Шатланып-сөенеп, балаларыңның, оныкларының хөрмәтен тоеп, мул тормышта бәрәкәтле гомер кичерсәң иде. Без сине бик-бик яратабыз!



*Төрле чакны күргәнсеңдер, әни,*
*Йөрәгеңдә күптер яра да.*
*Киңәшчебез, терәгебез булып,*
*Озак яшә безнең арада.*

**Иң җылы теләкләр белән улың Рива, киленең Найлә, оныгың Салават; кызың Гөлфирус, кияве Камил, оныклары Илдар, Галия; улың Рамил, киленең Лилия, оныгың Линар; улың Ринат, киленең Гөлнара, оныклары Радик, Илназ.**

**Хөрмәтле Таһирә Таһировна АЗИЗОВА!**

Мәгариф хезмәткәрләренең район профсоюз оешмасы һәм 3 нче номерлы “Чишмә” балалар бакчасы коллективы Сезне күркәм юбилеегыз 55 яшь тулу көнегез уңаеннан ихлас күңелдән тәбрик итәләр. Сезгә корычтай нык исәнлек, озын гомер телиләр. Күңел күгегез һәрчак аяз булсын, киләчәк көннәр Сезгә бары тик бәхет китереп ,тормышыгызда бары уңышлар юлдаш булсын. Фидакарь хезмәтегез өчен зур рәхмәт Сезгә.



*Шатлык тулып якты көннәр*
*Сезгә гел юлдаш булсын.*
*Бүгенге матур мизгелләр*
*Гел кабатланып торсын.*

**Югары Терешка авылында яшәүче Фәйзрахман Якубович ХАМЗИН 7 апрельдә гомер бәйрәмен - 75 яшьлек юбилеен каршы ала. Кадерле тормыш иптәшем, яраткан әтиебез, сөекле бабакаебыз!**



Без сине ихлас күңелебездән истәлекле юбилеең белән кайнар котлыйбыз һәм җир йөзендәге иң изге, йөрәктәге иң кадерле хисләребезне юллыйбыз. Синә булган чиксез хөрмәтебез йөрәгең түрендә урын алсын, кайгы-борчулар читләп үтсеннәр, ә туар таңнар бәхет - шатлыклар гына бүләк итсеннәр. Алга таба да әниебез белән бергә бала-оныкларыңның игелекләрен күреп, шатлыкта, исәнлектә, бәхеттә яшәвегезне телибез. Фәрештәдәй изге күңеленнән беркайчан да иман нуры сүнмәсен. Без сине чиксез яратабыз!



*Әтиебез – безнең кадерлебез,*
*Без бәхетле җирдә син барга.*
*Фәрештәләр кунсын иңнәреңә*
*Туган көнең белән котларга.*
*Төрле чакны күргәнсеңдер, әти*
*Йөрәгеңдә күптер яра да.*
*Киңәшчебез, терәгебез булып*
*Озак яшә безнең арада.*

**Иң җылы теләкләр белән тормыш иптәшең Кәмилә Сафиулловна, кызларың Фәридә-Радик, Лилия - Азат, улларың Фәрит-Рәмзия, Фатих - Гөлнара, оныкларың Раил-Гөлнара, Рәшит, Ләйсән, Илнар, Илдар, Алсу, Әминә, кода-кодагыйларың һәм барча туганнарың.**

Югары Терешка - Урта Терешка – Новоспасск.

**Иске Мостяк авылында тормыш итүче Тахир НАСЫРОВ 4 апрельдә 70 яшьлек юбилеен билгеләде. Иң кадерле кешебез – тугры тормыш иптәшем, газиз әтиебез, яраткан бабакаебыз!**



Гомер юлың якты өлге итеп алырлык, меңнәргә үрнәк булырлык кадерле әтиебез! Сине юбилеең белән кайнар котлыйбыз. Әниебез белән безне кадерләп, яратып-сөеп үстереп, олы тормыш юлына аяк басарга булышканыгыз, гаделлеккә өйрәткәнегез өчен зур рәхмәт сезгә. Син олы җанлы, киң күңелле кеше буларак, балаларыңа, туганнарыңа сабырлык, изгелек, шәфкатьлелек үрнәге күрсәтеп яшисең. Барысы өчен дә мең-мең рәхмәтләр сиңа!



*Әле һаман без дип яшисең син,*
*Күптән инде зурлар булсак та.*
*Аз булыр кук, әткәй, синең өчен*
*Нинди изгелекләр кылсак та.*

**Матур теләкләр белән тормыш иптәшең Равза, улың Илдар, кызың Найлә, киленең Гөлнара, кияве Фәнис һәм барча оныкларың.**

Иске Мостяк – Тольятти.

**Усть Кулатка авылында туып, шунда тормыш итүче, гомерен авылга багышлаучы, хөрмәтле кешебез Халим Исхак улы СӨЛӘЙМАНОВКА 80 яшь тула.**

**Хөрмәтлебез дин кардәшебез!** Без, мәчет картлары, Сезгә тыныч картлык, иман байлыгы, хәсрәтсез көннәр, сәламәтлек, җан тынычлыгы телибез. Шулай бөтен авыл халкына үрнәк булып, бала-оныкларыгызның назын, хөрмәтен, игелеген тоеп, озын-озак яшәгез



*Кешелекле бит Сез, олы җанлы,*
*Ярдәмчел Сез дуска, туганга.*
*Мәчетебез яктырып китә, сыман*
*Бу дөньяда тик Сез булганга.*

**Изге теләкләр юллап, “Ибраһим” мәхәлләсе картлары.**

**Иске Атлаш авылында гомер кичерүче Адельша Исхак улы МӨСЛИМОВКА 5 апрельдә 85 яшь тула. Хөрмәтле тормыш иптәшем, кадерле һәм сөекле әтиебез, бабакаебыз!**

Без сине олы юбилең – гомер бәйрәмең белән ихлас күңелебездән котлыйбыз. Сиңа исәнлек-саулык, озын гомер, иман байлыгы, кайгы-хәсрәтсез көннәр, әниебез белән тигезлектә, муллыкта, шатлык-сөенечләргә куанып, бәхетле яшәвеңне телибез. Алдагы гомереңне дә балаларыңның, оныкларыңның игелеген күреп, туганнарыңның хөрмәтен сизеп яшәргә Аллаһы Тәгалә насыйп итсен. Син, әти, безнең өчен һәрчак киң күңелле, мәрхәмәтле, ярдәмчел була белдең, тормышта безнең өчен зур таянычыбыз. Акыллы, тәпле киңәшләрең, яхшы тәрбияң өчен олы рәхмәтләребезне белдерәбез, сине чиксез хөрмәт итәбез.



*Котлы булсын кадерлебез юбилеең,*
*Шатлык балкып торсын йөзеңдә,*
*Безнең өчен бик тә кадерле син,*
*Рәхмәт яусын барысы өчен дә.*

**Иң җылы теләкләр белән тормыш иптәшең Рәисә Абдулловна, кызларың Рауза, Равилә, Венера, Адлия, кияүләрең Нияз, Александр, Шамил, 9 оныгың һәм 5 оныкчаң.**

Иске Атлаш – Югары Терешка – Самара - Ульяновск.

**Бахтеевка авылында гомер итүче Мингач кызы Зәврә КУРМАЕВА 8 апрельдә 80 яшьлек юбилеен билгели.**

**Безнең өчен иң кадерле, иң якын апабыз!** Без сине чын күңелдән юбилейлы туган көнең белән кайнар котлыйбыз. Сиңа нык исәнлек, озын гомер, тыныч тормыш, яшәүдән ямь табып, барлыкта - муллыкта, озак еллар безне ачык йөзең белән каршы алып, изге догалар укып юлга озатып яшәвеңне телибез. Син олы җанлы, киң күңелле таянычыбыз, киңәшчебез буларак, безгә сабырлык, изгелек, шәфкатьлелек үрнәге күрсәтеп яшисең. Барысы өчендә Ходай Тәгаләнең олы рәхмәтләре яусын.



*Ак бәхетләр алып килсен сиңа*
*Яз башында килгән пар кошлар.*
*Юбилееӊ котлы булсын диеп*
*Җибәрәбез сиңа алкышлар.*
*Сиңа булган чиксез хөрмәтебез*
*Урын алсын йөрәк түреңдә.*
*Шатлык куанычлар, зур бәхетләр*
*Юлдаш булсын сиңа гомергә.*

**Ихлас күңелдән энең Шәүкәт гаиләсе белән, сеңелләрең Рәисә, тормыш иптәше Якуб, балалары, оныклары белән, сеңелең Наилә гаиләсе белән.**

Бахтеевка - **Ульяновск - Самара - Уфа .**

**Урта Терешка авылында туып үскән, хәзерге вакытта Иске Кулатки бистәсендә гомер итүче Мәрьям Кәлимулла кызы АБУШАЕВА 8 апрель көнне үзенең 55 яшьлек юбилеен каршылый.**

Бу шатлыклы көнең – олы юбилеең белән сине чын күңелдән тәбрик итәбез. Кешелекле, мәрхәмәтле, гадел син. Бүген син безгә, балаларыңа, газиз әни, оныгыңа – кунакчыл әби, туганнарыңа – нык терәк. Без сине бик яратабыз һәм олы рәхмәтләребезне белдерәбез.



*Котлы булсын, кадерлебез, юбилееӊ,*
*Шатлык балкып торсын йөзеңдә.*
*Безнең өчен бик тә кадерле син,*
*Рәхмәт яусын барысы өчен дә.*
*Кайчак килсәк, ишек ачык була,*
*Каршылыйсың ачык йөз белән.*
*Авыр чакта җиңел булып китә*
*Синең әйткән җылы сүз белән.*

**Иң изге теләкләр белән җизнәң Абдулхак Сафиуллович, улы Эльнар, килене Лидия, оныгы Милана, шушы теләкләргә Венера-Фәһим Динюшевлар, Люөия-Марс Атауллиннар гаиләләре дә кушыла.**

Урта Терешка – Тольятти – Сызран.

**Иске Зеленай авылының "Югары оч" мәчете мәхәлләсенең ихтирамлы мөселманы Ризван улы Мохаррәм ВАГАПОВ 3 апрельдә үзенең 80 яшьлек олы юбилеен билгеләде.**

**Хөрмәтле дин кардәшебез!** Без сине “Югары оч” мәчете мөселманнары исеменнән чын күңелдән олы юбилееӊ белән кайнар тәбрик итәбез! Киләчәктә исәнлек-саулык, ак бәхетләр, җан тынычлыгы телибез. Мәчетебезгә йөреп, изге гыйбадәтләр кылуыңны телибез. Сез 22 елдан артык гыйбадәт юлында булып, мәчетебезне сафка бастыруда зур эшләр башкардыгыз. 20 елга якын мәхәлләбезнең рәисе вазифасын үтәп, “Җомга мәктәбе”н төзүне алып бардыгыз һәм бүген дә шушы мәктәптә дини белемегезне камилләштерәсез. Гомумән әйткәндә, авылыбызны, юлларны, кизләүләрне төзекләндерүдә дә Сезнең өлешегез шактый зур. Шушы изге гамәлләрегез, ярдәмче булган өчен, без Сезгә авыл халкы исеменнән олы рәхмәтләребезне укыйбыз.

Олы юбилеегыз уңаеннан озын гомер, иман байлыгы, күңел тынычлыгы белән пар канат булып, балаларыгызның, оныкларыгызның шатлыкларына куанып, аларның ярдәмен күреп, бәхетле картлыкта, гыйбадәттә яшәвегезне телибез.



*Юбилеегыз котлы булсын*
*Гыйбадәт кылыйк бергә.*
*Изгелекләр истә калсын*
*Мәңгелеккә гомергә.*

**Иске Зеленай авылының "Югары оч" мәчете мәхәлләсе һәм авыл халкы исеменнән Якуб улы Ибраһим Сафаров.**

**2017 ел - Ульяновск өлкәсендә Мәрхәмәтле эшләр елы**

# Рәхмәтебез чиксез

Кеше үзенең сәламәтлеге какшаудан бер дә гарантия бирә алмый. Ә инде олы яшькә җиткәч, моның турында бер дә шик юк һәм без исәнлегебезне ныгыту өчен шәфкать хезмәткәрләренә мөрәҗәгать итәбез.

Безнең белән дә нәкъ шулай килеп чыкты һәм дәва алыр өчен үзебезгә район больницасының терапия бүлегенең 5 нче палатасында ятырга туры килде. Бу бүлекнең табиблары Ә.Р. Масова, Р. Р. Азизова, А. Р. Кафизова, шәфкать туташлары Г. М. Сәләева, Г. И. Курамшина, И. К. Хамзина, Г. А. Исмаилова, Г. М. Хакимова, Г. Р. Мохамедова безнең турында кайгыртучанлык күрсәтеп, үзебезне дәваларга тырыштылар. Аларның ягымлы сүзләре дә йөрәгебезгә шифалы дару булып барды.

Гомумән, палатабыздагы чисталык, җылылык район больницасы хезмәткәрләренең авыруларны кайгырту турында ачыктан-ачык сөйләп тора. Дәвалану чорында без үзебезне бик яхшы хис итеп, бар уңайлыкларны сизеп яшәдек.

Авыруларга карата яхшы мөнәсәбәтләре, безне игътибарлы итеп дәвалаганнары өчен югарыда әйтеп үткән медицина хезмәткәрләренә “Күмәк көч”район газетасы аша олы рәхмәтләребезне белдерәбез.

**К. Х. РӘХМӘТУЛЛИН, Р. И. ЯФАРОВ, А. М. АВВӘСОВ, Җ. М. КАДЕРМӘТОВ.**

**Иске Кулатки эшчеләр поселогы.**

Гаилә кыйммәтләре

# Бала тәрбияләүдә этиләрнең роле



**Рәсемдә Иске Кулаткыдан күп балалы Балакиннар гаиләсе.**

Районыбызда эшләп килүче “Гаилә” үзәге белгечләре даими рәвештә гаиләләр, мәктәп укучылары белән төрле очрашулар, профилактик әңгәмәләр үткәрәләр. Шушы көннәрдә генә Иске Кулаткы район больницасының балалар консультациясендә дә педагог – психолог Г. Р. Рафикова гаиләләр белән очрашты һәм “Бала тәрбиәләүдә этиләрнең роле” темасына әңгәмә алып барды.

- Бүгенге көндә гаиләдә бала тәрбияләү эше һаман катлаулана бара. Моның сәбәбе күптөрле, әлбәттә. Балалар хәзер күбрәк күрәләр, күбрәк ишетәләр, күбрәк фикер йөртәләр. Ә ата-аналар ул шартларны искә алалармы соң? Билгеле, аларның күпчелеге үз балаларының киләчәге турында нык уйлана. Шулай да кайберәүләр балаларны тәрбияләүгә бөтенләй әһәмият бирми, тәрбия эшендә гафу ителмәслек, төзәтеп булмаслык ялгышлар җибәрә. Икенче берәүләр исә, балаларга кирәгеннән артык әһәмият биреп, аларны боза, балалар эгоист булып үсә. Гаилә баланың нинди булуына, дөньяга карашына, баланың әхлагына нигез сала. Ләкин бала тәрбияләү белән нигәдер күбрәк балалар бакчасы, мәктәп һәм әни кешеләр шөгыльләнә. Бүгенге гаиләдә этинең роле нинди соң? Ир кеше – гаиләнең хуҗасы, терәге. Яшь буынны тәрбияләүдә этиләр авторитеты гаять зур роль уйный. Инглиз шагыйре Джордж Гербет та: “Яхшы ата йөз укытучыдан да өстен”,- дип, юкка гына әйтмәгән. Әлбәттә, сүз күркәм, авторитетлы этиләр турында бара. Шуңа күрә авторитет, беренче чиратта, балага һәрьяклап уңай шәхси үрнәк күрсәтүгә, аны ихтирам итүгә, сүзенә, эш-гамәленә һәм тормыш тәҗрибәсенә инануга нигезләнергә тиеш. Бигрәк тә хәзерге чорда-балалар бакчаларында, мәктәпләрдә, мәктәпләрдән тыш учреждениеләрдә күпчелек хатын-кызлар эшләгән чорда балаларга ир-ат йогынтысына мохтаҗлык аеруча нык сизелә. Ата йогынтысы булмау элек - электән тәрбиягә зыян китергән. Балалар үзләрен физик чыныктырган, балык тотарга, йөзәргә, шашка-шахмат уйнарга һәм башка шундый һөнәрләргә өйрәткән аталарны якын күрәләр. Балалар физик көчлеләрне яраталар һәм рухи көчлеләр ягына омтылалар. Әгәр ата өй эшләреннән читләшсә, аның бу гадәтенә кызы һәм улы да тиз иярә. Өй мәшәкатьләрен акыл белән гаилә әгъзалары арасында бүлешкәндә генә тәрбия эше уңышлы бара. Хатынына игътибарлы ата улы һәм кызы өчен үрнәк була ала. Атаның балага мөнәсәбәте – аның әнисенә мөнәсәбәте ул. Димәк, эти кешенең гаиләдә үзен үзе тотуы иң беренче хәлиткеч фактор. Балалар – гаиләнең көзгесе дип юкка гына әйтмәгәннәр. Ата – баланың иң якын, иң кадерле кешесе. Ата булу – буыннарны югалтмыйча дәвам иттерү. Эти булган кеше зур хәреф белән башланган Эти булсын иде! Дустанә атмосферада үткән әлеге аралашу бер гаиләне дә битараф калдырмады. Соңыннан этиләргә файдалы мәгълүматлар тупланган буклетлар да таратылды.

**Гөлназ КУЗӘЕВА.**

# Чаралар белемгә күз ача



Март аенда Иске Мостяк урта мәктәбендә төрле бай чаралар гөрләп үтте.

27 февральдән 4 мартка кадәр мәктәп укучыларының “Сәнгать атналыгы” булып узды. Анда V- VIII класс укучылары төрле язучыларның шигырьләрен сәнгатьле итеп укыдылар, кызыклы викториналар ясадылар, КВН уеннары оештырдылар һәм шулай ук 8 март - Халыкара хатын –кызлар көненә багышлап, әниләргә концерт номерлары күрсәттеләр.

6-7 мартта башлангыч класс укучыларының атналыгы булып үтте. Бу атналыкны укытучылар И. С. Нугаева, Р. Р. Абдуллина, Л. Ә. Нугаева укучылар белән викториналар оештырдылар һәм экология буенча мастер-класс күрсәттеләр.

13- 18 мартта мәктәбебездә шулай ук математика атналыгы булып үтте һәм аны укытучы Г. К. Рәзәпова алып барды. Бу атналыкта укучылар математика буенча үзләренең белемнәрен күтәрделәр.

Март аенда шулай ук Павловка эшчеләр бистәсендә “Кече академия” дип исемләнгән башлангыч класс укучыларының зональ конкурсы булды. Анда Иске Мостяк урта мәктәбенең III класс укучысы Лилиана Хөсәенова “Минем авылым, синең исемеңдә нәрсә бар?” дигән тема буенча чыгыш ясады һәм “Кече академия”нең сертификатын алуга лаек булды.

Билгеле бу сертификатны алу өчен аның укытучысы Л. Ә. Нугаева Лилиана Хөсәенова белән шөгыльләнеп, зур эш башкарды.

**Зәкия ЗӘЙНЕТДИНОВА.**

**АДМИНИСТРАЦИЯ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ**
**«СТАРОКУЛАТКИНСКИЙ РАЙОН»**
**УЛЬЯНОВСКОЙ ОБЛАСТИ**

**П О С Т А Н О В Л Е Н И Е**

**«27»марта 2017 года** **р.п.Старая Кулатка** **№ 75**

**Об утверждении размера платы, взимаемой с родителей за присмотр и уход за детьми в муниципальных дошкольных образовательных организациях, муниципальных общеобразовательных организациях муниципального образования «Старокулаткинский район», реализующих образовательную программу дошкольного образования**

В соответствии с Федеральным законом «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации» от 06.10.2003 года №131-ФЗ, Законом Ульяновской области «О наделении органов местного самоуправления муниципальных образований Ульяновской области отдельными полномочиями по опеке и попечительству в отношении несовершеннолетних» от 05.07.2013 года №109-ЗО, Уставом муниципального образования «Старокулаткинский район», Федеральным Законом от 29.12.2012 № 273 - ФЗ «Об образовании в Российской Федерации», администрация муниципального образования «Старокулаткинский район»

**п о с т а н о в л я е т:**

1. Установить с 1 апреля 2017 года плату, взимаемую с родителей (законных представителей) за присмотр и уход за детьми в образовательных организациях, реализующих основную общеобразовательную программу дошкольного образования на территории муниципального образования «Старокулаткинский район», учредителем которых является администрация муниципального образования »Старокулаткинский район» в зависимости от присмотра и ухода за детьми (от времени пребывания воспитанников) в следующих размерах:

1.1. при режиме полного дня (9-часового пребывания) в размере 52 рублей за один посещенный ребёнком день.

1.2. при режиме полного дня (10,5-часового пребывания) в размере 73 рубля за один посещенный ребёнком день.

2. За присмотр и уход за детьми-инвалидами, детьми-сиротами и детьми, оставшимися без попечения родителей, а также за детьми с туберкулёзной интоксикацией, посещающих образовательные организации, реализующие общеобразовательную программу дошкольного образования, родительская плата не взимается.

3.Постановление администрации муниципального образования «Старокулаткинский район» № 569 от 22. 10.2015 г. «Об утверждении размера платы, взимаемой с родителей за присмотр и уход за детьми в муниципальных дошкольных образовательных организациях, муниципальных общеобразовательных организациях муниципального образования «Старокулаткинский район», реализующих образовательную программу дошкольного образования» признать утратившим силу.

4. Настоящее постановление вступает в силу с 1 апреля 2017г. и подлежит официальному опубликованию.

5. Контроль за исполнением настоящего постановления возложить на Заместителя Главы администрации по вопросам социального развития- начальника Управления образования администрации муниципального образования «Старокулаткинский район».

**Глава администрации** **И.А.Аблязов.**

Мәктәп тормышы

# Мавыктыргыч экскурсиядә



Иске Кулаткы беренче номерлы урта мәктәбенең С. А. Иксанова җитәкчелегендәге IV “А” сыйныф укучылары язгы каникулларын файдалы һәм мавыктыргыч итеп үткәрү максатыннан ДОСААФ автомәктәбендә экскурсиядә булдылар. Автомәктәп директоры Р. А. Джаметов балаларны каршы алды һәм мәктәпнең бинасы белән таныштырды. Әлеге уку йортының тарихы турында мавыктыргыч итеп сөйләде һәм балалар игътибарына “Юлларда куркынычсызлык кагыйдәләре” темасына видеофильм тәкъдим итте. Шуннан соң укучылар юл кагыйдәләре буенча компьютер аша төрле биремнәр үтәделәр. Ә инде биремнәрне үтәүдә укытучы – инструктор И. А. Ибраһимов зур ярдәм күрсәтте. Әлеге экскурсия вакытында балалар юл кагыйдәләрен өйрәнү буенча белемнәрен ныгыттылар һәм бик күп файдалы мәгълүмат үзләштерделәр.

**Гөлназ КУЗӘЕВА.**

# Ветераннарны котлыйбыз!

**2017 елның апрель аенда районыбызда гомер кичерүче Бөек Ватан сугышы ветераны Хияли Солтанович Тюкаев (Иске Кулаткы) үзенең туган көнен билгеләи.**

**Хөрмәтле ветеран!**

Район ветераннар Советы Сезне истәлекле туган көнегез белән тәбрик итә. Илебез азатлыгы өчен көрәштә күрсәткән батырлыгыгыз алдында баш иеп, Бөек җиңүне яулап кайтканыгыз өчен Сезгә олы рәхмәт белдерәбез. Исәнлек-саулык, җан тынычлыгы, шатлыклы көннәр телибез. Якыннарыгызның игелеген күреп, озын гомер итегез!

Район ветераннар Советы Бөек Ватан сугышының соңгы чакырылыш солдаты **Ислам Мөнирович Байбиков (Югары Терешка), Зәкәрья Сафиуллович Хайров (Яңа Терешка)** Бөек Ватан сугышының тыл хезмәтчәннәре **Җәфәр Алләмович Абәйдуллин (Яңа Зеленай), Шикюр Закирович Хәбибуллин (Югары Терешка), Әкрам Рамазанович Шәфиев (Урта Терешка), Алимә Мостафовна Абитова (Иске Атлаш), Адельша Исхакович Мөслимов (Иске Атлаш), Зарифә Иксановна Касымова (Яңа Кулаткы), Алия Хөсәиновна Башаева (Иске Атлаш), Мәсүдә Фатиховна Мохаммедова (Иске Мостяк).** Бөек Ватан сугышы елларында туган балалар статусын йөртүче һәм апрель аенда үзләренең олы юбилейларын билгеләп үтүче **Камил Солтанович Сәбитов (Мосеевка), Рима Гиоргиевна Аввәсова (Иске Кулаткы), Зәһидә Солтановна Алмакаева (Югары Терешка), Якуб Хөсәинович Алюшев (Иске Кулаткы), Рәхимә Мәсумовна Амирова (Яңа Кулаткы), Маһирә Шикюровна Бахитова (Иске Кулаткы), Мохаррәм Ризванович Вагапов (Иске Зеленай), Шәүкәт Ахатович Гафуров (Иске Мостяк), Разия Абубәкәровна Забирова (Карамалы), Тәүхидә Хөсәиновна Измайлова (Вязовый Гай), Зәврә Минһачевна Курмакаева (Бахтеевка), Гөлҗиһан Юнусовна Кузәева (Яңа Терешка), Рауза Абдулахатовна Кушаева (Иске Кулаткы), Сания Сөләймановна Мадьярова (Иске Кулаткы), Рафать Шикюрович Мостакаев (Яңа Терешка), Рауза Исмәгыйлевна Мохаммедова (Яңа Зимница), Рауза Хамидулловна Рамазанова (Иске Кулаткы), Халим Исхакович Сөләйманов (Усть Кулаткы), Мизбах Юсупович Сөнчәләев (Иске Мостяк), Тәскирә Батырхановна Тәминова (Кирюшкино), Фәйзрахман Якупович Хамзин (Югары Терешка), Петр Иванович Хурасев (Чуваш Кулаткы), Рушан Гафурович Шабуров (Вязовый Гай), Әкрам Рамазанович Шәфиев (Урта Терешка), Рауза Хайретдиновна Юнусованы (Яңа Зимница)** чын күңелдән олы бәйрәмнәре белән тәбрик итә.

**Хөрмәтле юбилярлар!**

Дәһшәтле сугыш елларында дөньяга килеп, шатлыклы, борчу-хәсрәтсез, михнәтсез балачактан мәхрүм булдыгыз. Әмма сугыштан соңгы елларында илебезне торгызуда, халкыбыз, киләчәк буын рәхәт тормышта яшәсен өчен, гомер барышында күп тырыштыгыз, үзегездән өлеш керттегез. Сезгә саулык-исәнлек, гаилә бәхете, җан тынычлыгы телибез. Киләчәк тормышыгызда да саулыкта, муллыкта, якыннарыгызның игътибарын, җылысын тоеп яшәргә насыйп булсын.

*Сезнең тормыш юлы – матур тарих,*
*Күпләр өчен үрнәк булырлык.*
*Рәхмәт, дибез, Сезгә чын йөрәктән*
*Сезнең гомер – безнең горурлык.*

Районыбызда гомер кичерүче хезмәт ветераннары **Руфия Бариевна Аксянова (Иске Кулаткы), Рушан Якубович Алиев (Иске Мостяк), Мәгрифә Мостафовна Ахтәмова (Мосеевка), Равил Сабирович Бакиев (Яңа Зимница), Рәшидә Модәрисовна Бигиева (Иске Кулаткы), Рәхимә Халиловна Мадьярова (Иске Кулаткы), Таһир Хабибуллович Насыров (Иске Мостяк), Рузидә Мөбәрәковна Рәхимова (Иске Атлаш), Рәисә Яхьевна Хамзина (Зирекле), Әкрам Усманович Ханбиков (Яңа Зеленай), Мәхмүдә Исхаковна Ханбикова (Иске Зеленай), Гөлмәрьям Фассаевна Шарипова (Урта Терешка)** 2016 елның апрель аенда үзләренең истәлекле 70 яшьлек юбилейларын билгеләп үтәләр.

**Кадерле хезмәт ветераннары, өлкән буын вәкилләре!**

Район ветераннар Советы Сезгә истәлекле юбилейларыгыз уңаеннан фидакарь хезмәтегез, ихтыяр көчегез, районыбызга булган ихлас мәхәббәтегез өчен рәхмәт һәм хөрмәт сүзләрен, котлауларын җиткерә! Сезгә чын күңелдән нык сәламәтлек, тынычлык, иминлек һәм бетмәс-төкәнмәс тормыш энергиясе телибез! Сезнең тормышта шатлыклы очрашулар күп булсын, туганнарыгыз һәм якыннарыгыз күңел җылысы белән шатландырып, Сезнең турында һәрвакыт кайгыртып, игътибар күрсәтеп яшәсен!

БЕРГӘЛӘП УКЫЙБЫЗ

# ÊӨÒÅÏ ÓÇÃÀÍ ÃÎÌÅÐ

## *Повесть*

**Зифа Кадырова**




Лилия каршысында утырган бу чибәр егетнең күз карашы астында үзен энәдә утырган кебек хис итте. Аның күзләре гел әнисенеке кебек, искитмәле матур, үзенә тартып тора, күзне алу кыен иде. Ул куе кашларын кушып конверттан күзен алмады. Анда «Улым, шушы балаларга ярдәм ит. Әниең», диелгән иде.

- Исемең ничек?

- Лилия.

- Нәрсә эшли беләсең?

- Минме? - диде Лилия аптырап.

- Сезгә эш кирәктер бит, әни сезгә ярдәм итәргә кушкан.

- Юк-юк, минем эшем бар, мин кибеткә кассир булып кердем, энем дә укып‘бетерде, ул да эшли. Мин бурычны гына китердем. Рушания апага рәхмәт әйтерсез.

Игорь, әллә күңеле тулып, маңгаен кулы белән ышкып алды, аннан авыр сулады.

- Сезнең әниегезгә ни булды?

- Әни үлде, ел булды инде. Рушания апа ни хәлдә?

- Минем дә әни үлде.

Лилия акрын гына урыныннан күтәрелде дә, кире лап итеп утырды. Игорьга текәлгән күзләре зур итеп ачылган, мөлдерәп яшь тулган, нидер әйтергә теле - тик иреннәре генә калтырый, сүзләре чыкмый. Лилиянең тамак төбенә утырган төер тын алырга бирми, хәтта буыла башлагандай тоелды, юка пәлтәсенең изүен йолкыды, көчкә телен әйләндереп:

- Юк, булмас, - кына дия алды.

Ул күзе сукырайган кеше кебек капшанып ишеккә атлады. Игорь да шул хәлдә иде, әнисе исенә төшсә, кычкырып елыйсы килә. Лилия чыгып китте, ә ул һаман исәңгерәп утыра бирде. Аннан хушына килеп Лилия артыннан ташланды. Офис алдындагы скамейкада бөкләнеп төшкән Лилия үксі-үкси елый иде. Игорь акрын гына аның янына килеп утырды да, кызны кочагына алды. Үзе тешләрен шыгырдатып, еламаска тырышты. Азрак тынычлана төшкәч, Лилияне үзенең машинасына утыртты.

- Лилия, миңа барысын яңабаштан сөйлә әле, мин әни турында сөйләгәннәрне тыңларга яратам.

- Мин әниеңә бик тә үпкәләдем, минем әниемне ул көндерде операциягә ятарга, әни шундук үлде, без дүрт бала калдык. Лилия тагын үксеп еларга тотынды. - Мин әниеңне кичерә алмадым. Ул ничә тапкыр килде, ул безгә ярдәм итеп торды, ә мин киреләндем, ул гына гаепле тоелды әнинең үлемендә. Кайгы аңымны томалады, хәзер кемнән гафу үтеним, ул да миңа рәнҗеп китте бит. Ул шундый чибәр, сабыр иде, мин аны чирледер дип уйламадым да. Ул килмәгәч, сагына башладым, тик тоткан акчаларны җыеп тутыргач кына эзләп табармын дип уйладым, мин аның кайда яшәгәнен дә белмәдем. Лилия Игорьга яшьле күзләре белән текәлде. - Нигә бу тормыш шулай авыр, нигә шундый яхшы кешеләр бу дөньяны ташлап китә, минем дә әни юк, синең дә әни юк, ничек яшәргә соң? Эх, белгән булсам болай буласын, Рушания апаның үлгәнче янында булыр идем. Ходаем, гафу үтенеп тә булмый бит. Ичмасам, сез мине гафу итегез.

- Мин ни өчен? - диде әнисенеке кебек тоныкк күкрәк тавышы белән.

- Әниегезне рәнҗеткән өчен. Рәнҗеттем, сөйләшик, балам, диде, ә мин... Лилия машинадан төште дә, елый-елый тукталышка таба атлады.

Игорь аны яшьле күзләре белән озатып калды. Игорь кире кабинетына керде, тагын өстәлдәге конвертка күзе төште, кабат-кабат укып чыкты, кадерләп кенә әнисе кагылган кәгазьне сыйпады. Үз алдына «Лилия» дип кабатлады. Конвертны әйләндереп карады, тик анда аларның офис адресы гына язылган. Ул да аптырап калды, каян табыйм дип кире тышка йөгереп чыкты, тукталышта беркем дә юк иде. Икенче көнне ул зур кибетләрнең бөтен кассаларын йөреп чыкты, өченче көнне тагын эштән соң кибетләрне әйләнде. Аннан ул бәләкәй кибетләргә күчте, бер атна йөрү берни дә бирмәде. Ул инде җир асты юлларыннан эзли башлады, анда да кибетләр бар бит. Шуннан чыгып килгәндә берәү аңа эндәште:

- Исәнме, Игорь энекәш, ни эш бетереп йөрисең, әтиең ни хәлдә?

- Самат абый, исәнмесез. Әти бик шәптән түгел, үз эченә бикләнеп яши. Тукта, Самат абый, бәлки син ярдәм итәрсең, - дип үзенең Лилияне эзләвен аңлатып бирде.

- Алайса, акылына килгән ул бала. Әйе, әниең бик борчылып китте ул балалар өчен. Әниең үлгәннән соң мин дә бармадым, минем дә ачуым килде әниеңне рәнҗеткәнгә. Әйтсәм әйтим, әниең үзенең зәңгәр тунын сатып акчасын шул балаларга бирде, укуларын бетерсеннәр дип. Эх, нинди олы йөрәкле кеше иде синең әниең. Бармы икән тагын андыйлар? Мин аны җир бизәгенә тиңли идем. Әниләре синең әниеңә балаларымны ташлама, дип үлгән, шуңа әниең үзен ул балалар алдында бурычлы итеп санады. Менә алайса шул бурычны әниең сиңа дә калдырган. Адресларын бирәм сиңа, мин күп йөрдем анда.

Игорь кичке якта эштән соң адрес белән Лилияләргә килде, тик өйдә кеше юк иде, көтеп утырырга булды. Тышта йомшак кына кар ява, әллә ни салкын да түгел. Игорь тәрәзәсеннән үткән-сүткәннәрне карап таныш кешесен көтте. Авыр гына ике сумка күтәргән таныш кешесен күргәч, машинасыннан чыкты.

- Исәнме, Лилия, - диде дә аның кулындагы сумкаларын алды. - Мин инде сине таба алмам дип курыккан идем, теге көнне адресыңны да сорап өлгермәдем.

Лилия ни әйтергә белмичә, каршысында торган су сөлеге кебек егеткә текәлде. Аның өстендәге кара пәлтәсенә, калын кара дулкын-дулкын чәчләренә кар бөртекләре кунып шаяра.

- Лилия, өегезгә чакырасыңмы?

Ул аптырап бер урында таптанды. Игорь сумкаларны күтәреп, үзе алдан атлады. Өйнең эче бик гади иде, шулай да һәрнәрсә урынында, бар җирдә тәртип. Лилиянең югалып калуын аңлап, хәленә керде.

- Иртәгә документларыңны ал да, офиска кил. Лилия Игорьга күзләрен күтәрде.

- Бу әнинең теләге, иртәгә мин сине офиста көтәм.

Ул борылып чыгып китте. Лилия өченче көнгә генә килде. Кыюсыз гына аның алдына дипломын китереп салды.

- Охо, кызыл диплом, ә нигә соң кассир булып киттең?

- Ә кем алсын мине, хәзер эшкә танышлык белән генә урнашырга була.

- Лилия, беләсеңме, минем бик авыр чор, минем дә тәҗрибәм аз, ярдәм ит. Син финанс эшләрен үз өстеңә ал инде. Менә теге карточка ул синеке, әни сиңа калдырган, аның теләге безнең өйдә закон иде. Сиңа хәзер безнең компаниянең зур белгече буларак, зур-зур кешеләр белән очрашырга туры киләчәк, шуңа күрә бөтен сәүдә эшен үз өстеңә ал да, кәгазьләрне карап чык, үз сүзеңне әйт.

Игорь аны бер атна күрмәде дә. Бер атна үткәч, ул папкалар кочаклап Игорь янына килеп керде. Ул хәйран күп эшләр эшләгән иде. Аның урынында эшләгән яшь хатын гел тегеләй болай тыз-быз йөреп, тәмәке тартудан башка әллә ни эшләгәне дә күренми иде. Лилия хаклы, монда эшләгәннәрнең барысы да диярлек әтисенең танышларының балалары иде. Лилия бу эш өстендә әллә бик каты эшләгәнгә, күз төпләре батып, йончып калган кебек тоелды. Ул кәгазьләрне алдына салды да, кайда ялгышлар бар, кайда отчетлар дөрес төзелмәгән - тезеп китте, болай бик кыюсыз күренсә дә, дәлилләрне бик катгый итеп аңлата белде. Игорь аны тыңлап утырып, кызыл дипломны юкка гына бирмәгәннәр моңа, дип нәтиҗә ясады. Тик коллектив аңа көлемсерәп, кимсетебрәк карады. Киеме бик гади, үзе сабый баланы хәтерләтә. Ә анда эшләгәннәр күбесе Игорь кебек бай гаиләдән булганга, үзенә бәреп әйтә башладылар. Иртәнге планеркада да мыскыл итеп утырган кебекләр, Игорьның моңа бик тә ачуы килә. Күпме түзәр бу кыз? Ә Лилия белемле булуы белән алдыра.

Яңа ел кичәсе җитте, эштә өстәл әзерләделәр, котладылар. Кайбер кызлар Игорьның муенына да асылына башладылар, мондый хәлләр булгалый бәйрәм кичәләрендә. Лилия азрак карап утырды да, шым гына җыенып кайтып китте. Юл буе кибетләрдә йөрде, туганнарына бүләкләр алды. Алган эш хакы ул уйлаганнан да яхшырак булып чыкты, төннәр буе дәреслек өстендә утыруы юкка гына китмәде. Үз эшеннән бик тә канәгать иде ул. Игорьны исенә төшергәч, үзалдына елмаеп куйды. Кайдан туа мондый матур кешеләр, ирләргә шундый чибәр булу ник кирәк инде? Иртән планеркада күтәрелеп карамаска тырыша, карасаң күзне аерып алып булмый, шуңа ул гел күзен аска төшереп утыра. Лилия өйгә кайтып керде дә, көзге каршысына килеп басты, урап куйган куе чәчләрен таратып җибәрде. Никтер чәч туздырып йөрергә ояла иде, әнисе гел әйтә килде: «Ат ялыдай ул чәчеңне туздырып йөрмә, җыеп йөр»,- диде. Менә шул гадәткә кереп калды да инде. Әзрәк буянырга да өйрәнсә дә начар булмас иде, бигрәк ябык, төссез кебек. Ярый, Яңа елдан соң үзгәрермен. Бүген ул бухгалтерия китаплары алып кайтты, шуларны актарып чыгарга кирәк. Кайдадыр чыгу юлы өстә генә ята кебек, һич очына чыга алмый, кемдер кайдадыр саннарны бутый - очы-очка ялганмый. Бөтен Яңа ел, аннан соң да шул саннар белән утырды. Эшли башлавына өч ай үтеп тә китте. Эзләнә торгач, тәки чокып чыгарды. Бик күп акчаларның кая киткәнен белгәч, акрын гына Игорьның алдына кәгазьләр салды. Берсүзсез тәртеп-тәртеп күрсәтте. Ире цехта начальник, хатыны монда офиста бухгалтерияны алып бара. Миллионнар читкә китә. Игорьның күзе шакмак булды. - Менә сиңа дуслар!

Кайтып әтисенә әйткәч, аның да каны кайнады, шуларның эшедер дип күзалдына да китерә алмады. Улына барлык кешеләрне алыштырырга кушты. «Ә теге кызны ычкындырма, яхшы эшчеләр җыю бик кыен ул, улым». Игорь сеңелесе белән сөйләшеп карарга булды.

- Алеся, Лилиягә ярдәм итәр идең, өс киеме бигрәк гади, мондагы кызлар буш башлары белән шуннан көлеп утыралар. Ярдәм ит син аңа, кибетләрдә йөрт, килешле киемнәр ал, чәчләрен берәр нәрсә эшләтегез.

Алеся Лилиянең каршы килүенә дә карамыйча, аның белән бер көн буе кибетләрдә, салоннарда йөрде. Икенче көнне 8 нче март бәйрәме алдыннан Лилия килеп кергәч, Игорь башын кашып куйды. Лилиянең оялчанлыгы бигрәк тә үзенә җәлеп итә иде. Алесяга Игорь баш бармакларын күтәреп күрсәтте, янәсе, во! Хатын-кызлар бәйрәмен бер кафеда үткәрергә булдылар. Иртәдән киенеп-ясанып килгән хатын-кызлар тирә-якка чәчкә, хушбуй исләре таратып, тегеләй дә болай чабыштылар. Лилия дә бик килешле костюм-чалбар киеп килгән, иңенә төшкән җитен чәче, әз генә косметика аны бик тә сөйкемле итеп үзенә тартып тора. Игорь Лилиягә карап әнисен исенә төшерде, ул да шулай тыйнак һәм оялчан булды, ул алар арасында ниндидер уртаклык барлыгын чамалап куйды. Кичке якта бөтенесе кафега җыена башладылар, тик алар арасында Лилияне күрмәгәч, тышка чыкты. Ишек төбендә чәчкәләр тоткан бер егет тора иде, чәчкәләре дә әллә ни бай түгел, киеме дә бик гади. Игорь, кемне көтә икән дип, читкә машинасы кырына барып басты, эчтән чыккан кызлар, «Игорь, без синең белән», дип аның машинасына кереп тулдылар. Иң соңгы булып Лилия чыкты да, теге егет янына килеп басты, алар кочаклашып бергә тукталышка китеп бардылар. Кызларның бер ачы теллесе: «Кара, безнең теге фәрештә дә үзе кебек бер йолкыш тапкан»,- дип куйды. Ә аларның беркемдә эше юк, култыклашып, көлешә-көлешә атлауларын белделәр. Игорь үзендә әллә нинди көнчелек кебек нәрсә тойды, никтер күңеле кителеп калды, кич буена эчен әллә ниткән корт кимерде. Ә Лилия кафега килмәде. Игорь икенче көнне чәчәкләр кибетенә барып, танышларына, Алесяга чәчәкләр алды, тагын уйланып торды да, бер кочак ак розалар бәйләме алды. Кибеткә кереп бер зур гына торт алып чыкты да, Лилияләрнең йортына борылды. Ул никтер бик тә дулкынлана башлады, теге егет белән чыгып киткән булса, дип тә уйлап куйды. Ишек төймәсенә басуга, ишекне теге егет килеп ачкач, эченнән ниндидер калтырау кебек нәрсә йөгереп үтте. Ә ул берни булмагандай, керегез, дип юл бирде. «Лилия, сиңа килгәннәр!» Аш бүлмәсеннән өй күлмәге өстеннән алъяпкыч кигән, башына ак яулык бәйләгән Лилия килеп чыкты. Игорьны күргәч, кып-кызыл булды, кулларын кая куярга белми дулкынланды. Ишек төбенә тагын әллә кемнәр чыгып, берәм-берәм исәнләштеләр дә кереп югалдылар. Тик теге егет кенә һаман аңа карап тора бирде. Лилия елмаеп: «Таныш булыгыз, минем энем Илдар. Әйдә, узыгыз, без бәйрәм өстәле әзерлибез, хәзер бәлеш пешә», - диде. Чынлап та, нинди таныш ис дип тора иде, әнисе бәлеш пешергәндә шундый тәмле ис чыга иде бит. Игорьга җан кереп китте, аның моннан чыгып китәсе килмәде.

- Монысы сезгә, - дип чәчкә белән тортны тоттырды. Лилия чәчәкләрне кочаклап тынсыз калды, матур итеп беренче тапкыр аның күзләренә карап елмайды.

- Безнең белән бәлеш ашарга калыгыз.

Игорь бераз карап торды да, өстен сала башлады.

- Мин бәлеш яратам, - дип елмайды.

Никтер аның бу өйдән китәсе килмәде, ниндидер гаилә җылылыгы тойды. Илдар, «әйдә, шахмат уйный торабыз»,- дип, зур якка чакырды. Аларны шундук башка балалар уратып алды, кем җиңә дип икегә бүленделәр. Игорь гомер буе шунда яшәгән диярсең, үзе кебек яшьләр, гөрләшеп уйнадылар, ашадылар. Үзенә күрә бик күңелле булды.

- Лилия, бүген бәйрәм бит, мин сине бүген кичке ресторанга чакырам.

Лилия куркып:

- Юк-юк, бармыйм, - дип тартыша башлады, - минем кияргә кичке күлмәгем дә юк.

- Булыр, кибеттә күлмәк бетмәгән, ә хәзер мин сине бер җиргә алып барам.

Игорь Лилияне кайчандыр әнисенә ярдәмгә килгән Анна янына алып барырга булды. Лилия бер дә үзе турында уйламый, вакыты да юктыр инде. Бер сәгатьтән Игорь алдына искитмәле сөйкемле, калын җитен чәчле кыз басып тора иде, өстенә кигән озын зәңгәр күлмәк тә күзләренә килешеп тора. Игорь аңа карап әнисенеке кебек битләрен чокырайтып елмайды: «Принцесса Лили». Бу Лилия өчен көтелмәгән шатлык иде, беренчедән, үз-үзенә бик тә ошады, икенчедән, шундый егет белән беррәттән бару үзе бер горурлык. Ресторанда Алеся белән Айрат аларга килеп кушылдылар. Алар барысы да бик гадиләр, аны үз итеп каршы алдылар. Игорь Лилияне парлы биюгә чакырды, кочагына килеп кергән бу ябык кына кызны чак кына үзенә тартты, никтер ул аңа якын, кадерле тоелды. Иелеп кызның күзләренә карады, аның күзләре искитмәле матур зәңгәр төстә, кашлары коңгырт. Егетнең карашын күтәрә алмый кыз кып-кызыл булды, күзләрен аска төшерде, Игорь бер сүз дә әйтмәде, чак кына үзенә тартты, аннан килгән сафлык күңеленә кереп урын алды.

Бәйрәмнәр үткәч, Лилия Игорьның күзенә бик чалынмаска тырышты. Ул аны бик күрәсе килсә дә, читтәрәк торырга тырышты. Игорь аның өчен буй җитмәс, тормышка ашмас хыял иде. Ул аңлый, Рушания апа васыять итеп калдырганга гына аларны кайгырта, ә шулай да йөрәкне йөгәнләп булмый, күрәсе килә. Тирә-яктагы кешеләр дә сизәрләр кебек, ераграк торырга кирәк. Күбәләк кебек януың бар. Төннәрен аның турында уйланырга ярата, ә иртәнге планерка вакытларында ишек төбендәрәк, кеше артына качыбрак утырырга тырыша.

Гөрләп яз килде, беренче май бәйрәмендәге ялларда Лилия балаларны җыеп, әниләренең каберенә барып кайтырга җыенды. Әтисе гел югалып-эчеп йөрсә дә, аны да табып алып кайтып, юындырып, чиста киемнәр кидереп, үзләре белән алырга булдылар. Алар җыенып урамга чыгуга, зур машина килеп туктады.

- Кая җыендыгыз? - диде Игорь алар арасында эчепяныт беткән ямьсез адәмгә карап.

- Зиратка, - диде Лилия.

- Әйдә, утырыгыз, үзем алып барам.

Игорь бүген бер нәрсәне аңлады - шушы кечкенә, ябык Лилиянең җилкәсенә өелгән йөкнең ничаклы авыр икәнен. Шушы кыз бала шуларның барысын тарта, ашата, киендерә. Әтисенең күренеп тора эчкече икәне, әти кеше терәк түгел иде аларга. Игорь бер Лилиягә, бер таптанып апаларына карап торган энеләренә карады.

- Кирәкмәс, Игорь Александрович, без үзебез генә.

- Чайкалып торган әтисен гәүдәсе белән яшерергә маташты, ә исерек үзе алдан кычкырып чыга.

- Илдар, төялегез тиз генә, безнең әле тагын барасы җир бар.

Балалар сөенә-сөенә машинага кереп тулдылар, әтиләрен дә бөтереп тыктылар.

Тимердән бик матур итеп сырлап ясалган кабер рәшәткәсен Илдар үзе ясап куйган иде. Лилия әнисенең каберен чистартып чыгарды, анда инде беренче чәчкәләр чәчәк атып утыралар. Ул алар янына тагын ниндидер кечкенә чәчкәләр утыртты, бик кадерләп-яратып әнисенең каберен сыйпады, чак кына иреннәре кыймылдады, күз яшьләрен сөртеп алды. Бөтенесе шым гына апаларын күзәтеп басып тордылар, әтиләре чайкалып үксеп куйды. Игорь беренче тапкыр чын йөрәгеннән шушы тал чыбыгы кебек кызны кызганды һәм олы хөрмәт белән карады. Зираттан чыккач, Игорь аларга карап:

- Нәрсә эшлибез, бүген бәйрәм, киттек урманга, төялегез,- диде. Балаларның шатлыктан күңелләре күтәрелеп китте. Лилия генә бик уңайсызланып утырды. Игорь зур кызыл кирпеч йорт алдына килеп туктауга, капка ачылып китте. Машина йорт уртасына кереп утырды. Лилия Игорьның җиңенә ябышты:

- Кирәкми, зинһар өчен кайтарып куй безне, без кермибез.

- Без кердек шул инде. Әйдәгез, малайлар, без ит кыздырабыз урамда, сез, кызлар, өйдә чәй әзерлисез.

Аларга каршы Айрат белән Алеся да чыктылар. Куркыпкаушап калган Лилиянең хәлен аңлап, Алеся килеп кочаклады.

- Менә ничек яхшы иттегез килеп. Әйдә, Игорь сине бәлешне бик оста пешерә дип мактады, - дип җитәкләп өйгә таба атлады.

Өйнең эче искитмәле иде, стенада зур портрет, шул портрет каршысында зур гына диван. Бәләкәй сеңлесе Лилиянең җиңеннән тартты:

- Кара, теге безгә килгән апа.

Лилия өстен дә салмыйча, сихерләнгәндәй шул портрет алдына килеп басты. Ул дердер килде, кычкырып елаудан тыелырга тырышты, булдыра алмады.

- Рушания апа, кичер мине, кичер, апакаем.

Лилия йодрыкларын тешли -тешли шым гына елады. Ишек төбендә аны күзәтеп торган Игорь белән Алеся тыймадылар, Игорь шым гына чыгып китте. Әтисе кайдадыр күренми, тагын теге почмактадыр инде дип, бакча буйлап эзләп китте.

- Әниеңнең тиеннәре килми, улым, күпме көтәм.

- Әти, әйдә, мин сине үземнең гаиләм белән таныштырам, бер көтү.

- Нинди гаилә?

- Теге кыз турында сөйләгән идем бит, менә бөтен гаиләсе белән төяп алып кайттым, кабул ит.

- Әниең калдыргач, кабул итәргә кирәк, улым.

Александр Иванович урамдагылар белән күреште дә, өйгә кереп китте. Диванда елап утырган Лилия янына килеп утырды, аның елап шешенгән битенә карап, үзенең дә күзенә яшь килде.

- Авыр, балам, бик авыр, андыйлар дөньяда бүтән юк. Александр Иванович Лилиянең кулын учына алды, аның да күзләрендә яшь иде.

Көнне бер яктан бик күңелле генә үткәрделәр, Лилия генә гел исерек әтисе өчен читенсенеп утырды. Ара-тирә әле күлмәк якасын рәтләде, әле колагына гына пышылдап, эчүдән тыярга тырышты. Лилиянең бөтен теләге - тизрәк моннан кайтып китү. Шулай да кич кенә кайтып китә алдылар. Игорь бүгенгә бер сүз дә әйтмәде. Тик ул үзе өчен нәтиҗә ясады: ышанычлы юлдаш булачак. Май азагында беркөнне эштән чыкканын көтеп торды да, машинага утырырга чакырды. Лилия уңайсызланып кына кире какмакчы иде дә, тирә- яктагы халыкны каратып торганчы дип кереп утырды.

- Лилия, сөйләшәсе бар, сайла: ресторанга барабызмы, я берәр урмандагы кафегамы?

- Ә монда гына сөйләшеп булмыймы соң?

- Юк, монда сөйләшә торган сүз түгел.

- Үзеңә кара, мин ресторан яратмыйм.

Игорь кайдадыр бер кечкенә аланлыкта туктады, артта яткан розаларны аның алдына чыгарып салды.

- Туган көнең белән!

- Ә сез кайдан белдегез?

- Мин булачак хатынымның туган көнен генә белергә тиештер бит инде. Лилия аптырап текәлеп катты. - Лилия, озатышып йөрергә вакыт та юк, әйдә өйләнешик, чык миңа кияүгә.

**Дәвамы бар.**

## 10 Понедельник апреля

6.00 «Доброе утро»
10.00, 13.00, 16.00, 2.00, 4.00 «Новости»
10.20 «Контрольная закупка»
10.50 «Жить здорово!»
11.55 «Модный приговор»
13.15, 4.40 «Наедине со всеми» (16+)
14.20, 16.15 «Время покажет» (16+)
17.00 «Мужское / Женское» (16+)
18.00 «Давай поженимся!» (16+)
19.00 «Первая Студия»
21.00 «Пусть говорят»
22.00 «Время»
22.35 Т/с «НАЛЕТ»
0.35 «Вечерний Ургант»
1.00 «Познер»
2.15, 4.05 «Х/Ф «ШАКАЛ» (16+)

**РОССИЯ 1**

6.00, 10.15 «Утро России»
10.00, 12.00, 15.00, 18.00, 21.00 Вести
10.55 «О самом главном» (12+)
12.40, 15.40, 18.20, 21.45 Местное время. Вести
12.55 Т/с «СКЛИФОСОВСКИЙ» (12+)
15.55 Т/с «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» (12+)
18.40 «Прямой эфир»
19.50 «60 Минут»
22.00 Т/с «ТОРГСИН»
0.15 «Специальный корреспондент»
2.45 Т/с «В ЛЕСАХ И НА ГОРАХ» (12+)
4.40 Т/с «ДАР» (12+)

## 11 Вторник апреля

6.00 «Доброе утро»
10.00, 13.00, 16.00, 2.15, 4.00 «Новости»
10.20, 5.10 «Контрольная закупка»
10.50 «Жить здорово!»
11.55 «Модный приговор»
13.15, 4.15 «Наедине со всеми» (16+)
14.20, 16.15 «Время покажет» (16+)
17.00 «Мужское / Женское» (16+)
18.00 «Давай поженимся!» (16+)
19.00 «Первая Студия»
21.00 «Пусть говорят»
22.00 «Время»
22.35 Т/с «НАЛЕТ» (16+)
0.35 «Вечерний Ургант»
1.10 Т/с «САЛАМ МАСКВА» (18+)
2.30, 4.05 Х/ф «КОВБОЙШИ И АНГЕЛЫ» (12+)

**РОССИЯ 1**

6.00, 10.15 «Утро России»
10.00, 12.00, 15.00, 18.00, 21.00 Вести
10.55 «О самом главном»
12.40, 15.40, 18.20, 21.45 Местное время. Вести
12.55 Т/с «СКЛИФОСОВСКИЙ» (12+)
15.55 Т/с «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» (12+)
18.40 «Прямой эфир»
19.50 «60 Минут» (12+)
22.00 Т/с «ТОРГСИН»
0.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 2.45 Т/с «В ЛЕСАХ И НА ГОРАХ» (12+)
4.40 Т/с «ДАР» (12+)

**Агроферма "ЗЛАТОНОСКА" реализует КУР-НЕСУШЕК. Бесплатная доставка. Тел.: 89054555897.**

## 12 Среда апреля

6.00 «Доброе утро»
10.00, 13.00, 16.00, 2.15, 4.00 «Новости»
10.20, 5.05 «Контрольная закупка»
10.50 «Жить здорово!»
11.55 «Модный приговор»
13.15 «Наедине со всеми»
14.20, 16.15 «Время покажет» (16+)
17.00 «Мужское / Женское» (16+)
18.00 «Давай поженимся!» (16+)
19.00 «Первая Студия»
21.00 «Пусть говорят»
22.00 «Время»
22.35 Т/с «НАЛЕТ» (16+)
0.35 «Вечерний Ургант»
1.10 Т/с «САЛАМ МАСКВА» (18+)
2.30, 4.05 Х/ф «ОБРАТНАЯ ТЯГА» (16+)

**РОССИЯ 1**

6.00, 10.15 «Утро России»
10.00, 12.00, 15.00, 18.00, 21.00 Вести
10.55 «О самом главном» (12+)
12.40, 15.40, 18.20, 21.45 Местное время. Вести
12.55 Т/с «СКЛИФОСОВСКИЙ» (12+)
15.55 Т/с «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» (12+)
18.40 «Прямой эфир»
19.50 «60 Минут» (12+)
22.00 Т/с «ТОРГСИН»
0.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым»
2.45 Т/с «В ЛЕСАХ И НА ГОРАХ» (12+)
4.40 Т/с «ДАР» (12+)

## 13 Четверг апреля

6.00 «Доброе утро»
10.00, 13.00, 16.00, 2.15, 4.00 «Новости»
10.20 «Контрольная закупка»
10.50 «Жить здорово!»
11.55 «Модный приговор»
13.15, 4.55 «Наедине со всеми» (16+)
14.20, 16.15 «Время покажет» (16+)
17.00 «Мужское / Женское» (16+)
18.00 «Давай поженимся!» (16+)
19.00 «Первая Студия»
21.00 «Пусть говорят»
22.00 «Время»
22.35 Т/с «НАЛЕТ» (16+)
0.35 «Вечерний Ургант»
1.10 Т/с «САЛАМ МАСКВА» (18+)
2.30, 4.05 Х/ф «АННА КАРЕНИНА» (12+)

**РОССИЯ 1**

6.00, 10.15 «Утро России»
10.00, 12.00, 15.00, 18.00, 21.00 Вести
10.55 «О самом главном» (12+)
12.40, 15.40, 18.20, 21.45 Местное время. Вести
12.55 Т/с «СКЛИФОСОВСКИЙ» (12+)
15.55 Т/с «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» (12+)
18.40 «Прямой эфир»
19.50 «60 Минут» (12+)
22.00 Т/с «ТОРГСИН»
0.15 «Поединок» (12+)
2.15 Т/с «В ЛЕСАХ И НА ГОРАХ» (12+)
4.10 Т/с «ДАР» (12+)

## 14 Пятница апреля

6.00 «Доброе утро»
10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Новости»
10.20, 5.10 «Контрольная закупка»
10.50 «Жить здорово!»
11.55 «Модный приговор»
13.15 «Наедине со всеми»
14.20, 16.15 «Время покажет» (16+)
17.00 «Мужское / Женское» (16+)
18.00 «Жди меня»
19.45 «Человек и закон»
20.50 «Поле чудес»
22.00 «Время»
22.30 «Голос. Дети»
0.15 «Вечерний Ургант»
1.00 «The Rolling Stones». Концерт на Кубе»
3.10 Х/ф «НЕЦЕЛОВАННАЯ» (16+)
5.45 Х/ф «УКРОЩЕНИЕ ОГНЯ» (12+)

**РОССИЯ 1**

6.00, 10.15 «Утро России»
10.00, 12.00, 15.00, 18.00, 21.00 Вести
10.55 «О самом главном» (12+)
12.40, 15.40, 18.20, 21.45 Местное время. Вести
12.55 Т/с «СКЛИФОСОВСКИЙ» (12+)
15.55 Т/с «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» (12+)
18.40 «Прямой эфир»
19.50 «60 Минут» (12+)
22.00 «Юморина»
0.20 Х/ф «БУДУЩЕЕ СОВЕРШЕННОЕ»
2.20 Х/ф «МОЛЧУН»
4.15 Т/с «ДАР» (12+)

## 15 Суббота апреля

7.00, 11.00, 13.00, 19.00 «Новости»
7.10 Х/ф «УКРОЩЕНИЕ ОГНЯ» (12+)
9.00 «Играй, гармонь любимая!»
9.45 «Смешарики. Новые приключения»
10.00 «Умницы и умники»
10.45 «Слово пастыря»
11.15 «Алексей Леонов. Первый в открытом космосе»
12.20 «Смак» (12+)
13.15 «Идеальный ремонт»
14.15 «На 10 лет моложе»
15.00 «Голос. Дети»
16.50 «Вокруг смеха»
19.15 «Кто хочет стать миллионером?»
20.10 «Минута славы». Новый сезон»
22.00 «Время»
22.30 «Сегодня вечером»

**РОССИЯ 1**

6.15 Т/с «ЧОКНУТАЯ»
8.10 «Живые истории»
9.00, 12.20 Местное время. Вести
9.20 Россия. Местное время (12+)
10.20 «Сто к одному»
11.10 «Пятеро на одного»
12.00, 15.00 Вести
12.40 «Измайловский парк» (16+)
15.20 Х/ф «СЕРДЕЧНАЯ НЕДОСТАТОЧНОСТЬ» (12+)
17.20 «Золото нации»
19.00 «Субботний вечер»
21.00 Вести в субботу
22.10 Х/ф «РАЙ» (16+)
0.30 «Пасха Христова»
3.30 Х/ф «Я БУДУ РЯДОМ» (12+)

## 16 Воскресенье апреля

7.00, 11.00, 13.00 «Новости»
7.10 «Доброе утро»
9.05 «Смешарики. ПИН-код»
9.25 «Часовой» (12+)
9.55 «Здоровье» (16+)
11.15 «Непутевые заметки» (12+)
11.35 «Пока все дома»
12.25 «Фазенда»
13.10 «ТилиТелеТесто»
14.35 «Теория заговора»
15.25 «Романовы» (12+)
17.35 «ДОстояние РЕспублики: Алла Пугачева»
19.30 «Аффтар жжот»
20.30 «Лучше всех!»
22.00 «Воскресное «Время»
23.30 «КВН». Высшая лига» (16+)

**РОССИЯ 1**

8.00 М/с «Маша и Медведь»
8.30 «Сам себе режиссёр»
9.20, 4.25 «Смехопанорама»
9.50 «Утренняя почта»
10.30 «Сто к одному»
11.20 Местное время. Вести. Неделя в городе
12.00, 15.00 Вести
12.20 «Смеяться разрешается»
14.10 «Семейный альбом» (12+)
15.20 Х/ф «ЗАПАХ ЛАВАНДЫ» (12+)
19.00 «Танцуют все!»
21.00 Вести недели
23.00 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» (12+)
1.30 «Три святыни. Тайны монархов»
2.25 Т/с «ЖЕНЩИНЫ НА ГРАНИ» (12+)

Закон и порядок

# "Нетрезвый водитель", "Автокресло детям"



24 марта 2017 года ОГИБДД МО МВД России «Павловский» проведена профилактическая операция «Нетрезвый водитель». В ходе операции сотрудники ГИБДД осуществляли массовые проверки водителей на предмет управления транспортными средствами в состоянии алкогольного и наркотического опьянения. Основная цель операции - снижение числа аварий по вине пьяных водителей, а также выявление водителей, управляющих транспортом, в состоянии опьянения. Данных фактов не выявлено.

17 марта 2017 года проводилась специальная профилактическая операция «Автокресло детям!». Главной ее целью является профилактика детского дорожно-транспортного травматизма на дорогах района. Одной из основных задач ГИБДД будет напоминание взрослым участникам дорожного движения об использовании детских удерживающих устройств и об их ответственности за обеспечение безопасности детей в процессе дорожного движения. Выявлено два нарушения по статье 12.2.3 ч.3 КоАП РФ.

Дети-пассажиры являются самыми беззащитными участниками дорожного движения, у них нет возможности повлиять на развитие ситуации на дороге, а организм ребенка еще не достаточно крепок, чтобы перенести последствия даже самого незначительного ДТП. Во время проведения данной профилактической операции, экипажи ДПС будут усиленно нести службу в местах скопления детей (детские сады, школы, детские площадки и т.д.).

**Р.Д, ЮСУПОВ, Инспектор по пропаганде БДД ОГИБДД МО МВД России «Павловский», старший лейтенант полиции.**

7 апрель - Бөтендөнья сәламәтлек көне

# Салкын тидергәнсез икән...



Язгы кояш алдата. Тәрәзә аша карасаң, җылы кебек. Урамга чыксаң, салкын. Кыш белән яз очра кан көннәрдә күпләр салкын тиюдән җәфалана. Чи эләксә, нишләргә?

Салкын тигән чакта пар ингаляцияләре ярдәмгә килүен күпләр белә. Ә менә аны ничек дөрес итеп ясарга икәнлеген бел¬мәүчеләр дә бардыр әле Грипп котырган чорда хәлегезне җиңеләйтү макса тында ингаляция ясарга уйласагыз, түбәндәгеләрн белү хәерле.

Пар ингаляциясен тән температурасы 37,5 град стан артканда ясарга ярамый. Шулай ук гипертони йөрәк авыруларыннан интегүчеләргә дә бу тыелган. Ингаляция вакыты 15 минуттан да артырга тиеш түгеллеген дә белеп торыгыз. Балалар өчен бу вакыт — 5 минут. Аны көненә 1-2 тапкырдан да артык ясарга ярамый. Балаларга ингаляцияне 2-3 яшьтән алып һәм олы кеше күзәтүе астында гына ясыйлар. Шифасы күбрәк тисен, дип, кайнап утыручы су өстенә үк иелеп ингаляция ясау катгый тыела. Аны су кайнап чыгып 5 минут үткәннән соң (балалар өчен – су кайнап чыкканнан соң 10 минуттан) гына ясарга керешергә кирәк. Өске тын юлларын дәвалау максатында лаванда, мәтрүшкә, ромашка, шалфей һәм үги ана яфрагы төнәтмәләреннән файдаланалар. Берничә төрле үләнне бергә кушканда файдасы күбрәк була. Төнәтмә ясау өчен 1 аш кашыгы үлән чималын 250 миллилитр су белән кушып төнәтергә кирәк. Төрле эфир майларын һәм төнәтмәләрне кайнатырга куйган суга башта ук салып җибәрергә кирәк. Аларны кайнап утыручы суга соңыннан салып җибәрү дөрес түгел.

Тамакны еш чайкау да хәлне җиңеләйтә. Ромашка, шалфей, бөтнек һәм тырнак гөл төнәтмәләре — сыналган чаралар. Суган кабыгыннан да файдаланырга була. 3 чәй кашыгы суган кабыгын кайнап чыккан ярты литр суга салып, берничә минут кайнатып алалар һәм 4 сәгатьләп төнәтәләр. Сөзеп, шуның белән тамакны чайкыйлар.

**Фәүзия БАХТИЯРОВА, табиб-терапевт.**

## ООО «Немецкие оконные изделия»



1. Заводское производство.
2. Гарантия качества.
3. Короткие сроки.
4. Установка входных и межкомнатных дверей.
5. Выезд на замер бесплатно.

При заказе 3 окон - жалюзи в подарок
При заказе 4 окон - дверь входная в подарок.
При заказе 5 окон - шестое окно в подарок.

Рассрочка и скидки!!!

*Условия акции по тел.: 89020040102; 89374588644; 89278018665.*

*Супер акция - окно из прорфиля 70 мм. по цене окна из профиля 58 мм.*




## Стоматология ООО «Дента Люкс»



приглашает вас воспользоваться качественными услугами современной стоматологии

пациентам нуждающимися в протезировании готовы предложить:
- съемное протезирование: протезы из акриловых пластмасс, бюгельные, нейлоновые;
- несъемное протезирование: коронки с покрытием, металлокерамические, комбинированные, цельнолитые и.т.д.

**Запись предварительно по тел.: 89278033404, Пионерская, 18 А. Консультация бесплатно.**

## ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА

**от производителя.**
**НАТЯЖНЫЕ ПОТОЛКИ НЕДОРОГО.**
**РАССРОЧКА.**
**Просто позвони.**
**Телефон: 89272125484.**

## ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА

**Производство и установка пластиковых окон.**

**При заказе пяти окон, шестое – бесплатно! Замер, доставка – бесплатно.**

*Наше качество и доступные цены порадуют вас! Пенсионерам – дополнительная скидка!*



20% скидка

**Телефон: 8-937-278-05-55.**
Павловка.


**Уважаемые жители района!**

В нотариальной конторе по адресу: р.п. Старая Кулатка, ул. Куйбышева, д. 26, кв.1 ведет приём нотариус Хайбуллов Альберт Ренатович. Режим его работы с 3 апреля 2017 года: понедельник и четверг с 9.00 до 16.00ч., обед с 12.00 до 13.00ч., тел.: 89093564040.





11 апреля с 12 до 13ч. в аптеке №35 по адресу: р. п.Старая Кулатка, ул. Пионерская 6 состоится продажа
**СЛУХОВЫХ АППАРАТОВ.**
зауш:6500-9900 р.;карман. Siemens:7900р.; цифр.:12900-15000р.
Возможен выезд на дом.
Тел.: 8-912-723-51-88.
Реклама.Имеются противопоказания. Проконсультироваться со специалистом.



● Окна от производителя
+ комплектующие
● Двери «Бульдорс»
● Натяжные потолки (от 240 руб./в.м)

**Телефоны: 88422(651832), 89041823507, 89374550649.**


# Вниманию фермеров Ульяновской области!

Министерство сельского, лесного хозяйства и природных ресурсов Ульяновской области информирует о начале приёма документов от глав крестьянских (фермерских) хозяйств для участия в 2017 году в конкурсном отборе на получение грантов на поддержку начинающих фермеров и на развитие семейных животноводческих ферм на базе КФХ.

**Документы принимаются с 10 апреля 2017 года в рабочие дни (с понедельника по пятницу) ежедневно с 8.00 до 17.00ч. (обед 12.00 до 13.00ч.) по адресу: г. Ульяновск, ул. Радищева, 5, 1 этаж, 16 каб.**

Требования для участия в конкурсном отборе, необходимый пакет документов, формы документов, показатели оценки бизнес-планов размещены на официальном сайте Министерства www.agro-ul.ru в разделе «Начинающий фермер», 2017 год.

**Дополнительную информацию можно получить по телефону: 8(8422) 44-35-19,** контактное лицо - Хакимова Ильмира Рамазановна (главный специалист-эксперт Министерства сельского, лесного хозяйства и природных ресурсов Ульяновской области)

Продаются дрова. Цена договорная. Телефон: 89084870405.

Продаем гаражи металлические (пеналы) новые и б/у. Размеры любые. Доставка бесплатная. Цена от 26 тыс. руб. Тел.: 89063969864; 88007009091.

В р.п. Радищево ИП «Рамаев Д.А.» принимает заявки на суточных и подрощенных бройлеров, индюшат, гусят, утят и мулардов на март, апрель и май. Телефоны: 89278035043, 884239 22-6-16.

В р.п. Старая Кулатка продается дом площадью 60 кв. м. по ул. Нижне-Северная. Участок 27 сот. Газовое отопление. Центральное водоснабжение. Цена 550 тыс. руб. Тел.: 8-929-797-34-34; 8-927-833-19-99.

ООО "КС-Техсервис" реализует автотракторные запчасти для МТЗ, Т-40, ЮМЗ, Т-150, для автомобилей ГАЗ, УАЗ, а также большой ассортимент запчастей для почвообрабатывающей, посевной и сеноуборочной техники. Организация проводит диагностику инжекторных двигателей автомобилей ГАЗ, УАЗ. Адрес: р.п. Новоспасское, ул. Терешковой д 16 (около МРЭО). График работы: понедельник-пятница с 8.00 до 18.00 часов, суббота-воскресенье с 8.00 до 16.00 часов. Телефон: 8(84238) 2-34-06, 8927- 634 - 47- 24.

Продается сруб бани размером 6х3 пятистенка. Телефоны: 89279869668, 89084715531 - Ринат.

## Төзәтү

Иске Кулатки сугыш һәм хезмәт ветераннары Советы, "Кумәк көч" газетасының 22 мартта чыккан 12 номерлы санында кайгы уртаклашуны дөрес түгел дип аңлата һәм Иске Кулаткыда гомер кичерүче сугыш елы баласы, хезмәт ветераны Фәридә Абдулловна Халиковадан гафу үтенә.

**Павловская районная больница оказывает услуги**

по освидетельствованию на право ношения оружия и на допуск к управлению транспортного средства.
Водительская справка – 531р.
Справка на оружие – 351р.
ЭЭГ (электроэнцефалография) – 850р.

Прием по предварительной записи, тел.: 8927-827-23-19.


Директор-баш редактор М.С. МАСИЕВА.

Адрес редакции, издателя: 433940 р.п. Старая Кулатка Ульяновской области, ул. Куйбышева, 22.
ОАУ Редакция газеты "Кумяк кюч".

Телефоннар:
электрон адрес: kumiakk@mail.ru
884(249)2-11-94-редактор, факс, бухгалтерия;
884(249)2-12-64 - журнали - стлар, реклама бүлеге, РИК операторлары.

Индекс 54505.
Газетаны басарга кул кую вакыты: график буенча - 16.00 фактта - 16.00
Тираж 2800
Заказ № 13/14
Распространяется по подписке.

Газета отпечатана с готового оригинала-макета в ООО «Принт Хаус» 432071, г. Ульяновск, ул. Федерации, 15.

Элемтә һәм масса - күләм коммуникацияләр сферасында күзәтү буенча Федераль служабаның Ульяновск өлкә идарәсе 2014 елның 21 ноябрендә ПИ №ТУ73-00388 номерлы масса-күләм информация чарасын регистрацияләү таныклыгы белән регистрацияләнде.
Газета битләренә урнаштырылган рекламалар һәм белдерүләр өчен редакция җаваплылык тотмый.
Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
Хатлар, кулъязмалар һәм рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.